ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ һӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ
АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЫ

БАШЛАНГЫЧ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЫ ТАЛӘПЛӘРЕ НИГЕЗЕНДӘ ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛЕ БУЕНЧА УКУ БИРЕМНӘРЕ

Дидактик материаллар
1 нче сыйныф

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

БАШЛАНГЫЧ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ФЕДЕРАЛЬ ДӘҮЛӘТ БЕЛЕМ БИРҮ СТАНДАРТЫ ТАЛӘПЛӘРЕ НИГЕЗЕНДӘ ТУГАН (ТАТАР) ТЕЛЕ БУЕНЧА УКУ БИРЕМНӘРЕ

Дидактик материаллар

1 нче сыйныф

Казан
2024

ББК 74.268

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 нче елның 25 августында 730 нчы номерлы карары белән расланган “Татар халкының милли тәңгәллеген саклап калу” Татарстан Республикасы дәүләт программасы кысаларында басыла

Төзүчеләр: Шәмсетдинова Р.Р., ТРМҮИ татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, доцент, филология фәннәре кандидаты; **Җамалетдинова З.И.,** ТРМҮИ башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты.

Башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләре нигезендә туган (татар) теле буенча уку биремнәре: дидактик материаллар. 1 нче сыйныф / төз. Шәмсетдинова Р.Р., Җамалетдинова З.И. — Казан: ТРМҮИ, 2024. — 78 б.

“Башлангыч гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандарты таләпләре нигезендә туган (татар) теле буенча уку биремнәре” исемендәге дидактик материал Федераль дәүләт белем стандарты таләпләренә нигезләнеп эшләнде, төп дәреслекләргә өстәмә куллану әсбабы буларак тәкъдим ителә. Дидактик материалга туган (татар) теле программасының укыту бүлекләре буенча уку биремнәре тупланган. Әлеге әсбап туган (татар) теле дәресләрендә үзләштерелгән белемнәрне ныгыту, системалаштыру һәм шулай ук контрольдә тоту өчен тәкъдим ителә. Дидактик материал укытучыга укучыларның мөстәкыйль эшен оештыруда ярдәм итә.

© ТРМҮИ, 2024

1. «Туган телдә дәшсәм генә» шигырен укы. Шигырь нәрсә турында? Тел ни өчен кирәк?

Иң татлы тел — туган тел,
Анаң сөйләп торган тел
Туган телдә дәшсәм генә...
Сайрый тургай туган телдә,
Шатлык түгелә.

Тургай җыры, тургай моңы
Минем күңелдә.
Җырлый бүген бөтен дөнья
Тургай телендә.

Мин кушылып җырлыйм аңа
Туган телемдә.
Туган телдә җырлый чишмә,
Туган телдә шаулый таллар.

Туган телдә дәшсәм генә,
Туган халкым мине аңлар.

Разил Вәлиев

2. Шигырь юлларын укы. Татар теле нинди тел? Сорауга төшеп калган сүзләрне табып, җавап яз.

Татар теле — анам теле,
Иң борынгы бабам теле.
Буыннардан буыннарга
Күчеп килгән заман теле.
Татар теле — ... теле, ... теле, ... теле.

3. Мәкальләрне укы, мәгънәсен партадашың белән бер-берегезгә аңлатыгыз.

Тел — белемнең ачкычы, акылның баскычы.
Тел күрке — сүз.

4. Сорауларга җавап яз.

— Синең туган телең нинди?
— Татар телендә син кемнәр белән аралашасың?
— Татар телендә нинди телевизион тапшырулар карыйсың?
— Сезнең сыйныф укучылары нинди телдә аралаша?

5. Җөмләләрне укы. Рәсемдә чагылдыр.

Татар халкының туган теле — татар теле.	
Чәкчәк, өчпочмак, гөбәдия — татар халкының милли ризыклары.	
Казан — Татарстанның башкаласы.	
Татарларның милли киемнәре матур.	

6. Тел турында табышмаклар табып яз. Табышмаклардагы мәгълүматны сыйныфташларыңа сөйләргә әзерлән.

7. Рәсемнәр буенча җөмләләр төзе.







8. Рәсемнәр буенча төзегән җөмләләрне ике төркемгә бүлеп яз. Җөмләдә нинди сөйләм турында сүз барыр?

9. Сорауларга җавап яз. Син язган җөмләләр нинди сөйләм төренә кергәнен әйт.

— Синең туган илең ничек атала?
— Син кайсы шәһәрдә (авылда) яшисең?
— Синең туган телең нинди?
— Син яшәгән җирдә нинди милләт кешеләре яши?

10. Рәсем буенча сораулар ярдәмендә сөйлә. Сөйләм төрен билгелә.


Рәсемдә елның кайсы фасылы сурәтләнгән? Көн нинди? Малайлар нәрсә эшли? Рәсемгә нинди исем бирерсең?

11. «Яз» темасына караган җөмләләрне күчереп яз. Ул җөмләләрдә вакыйга бер үк вакытта башкарыламы? Яз айларына бәйләп аңлатып бир.

1) Мин бакчада суган утырттым. 2) Тәрәзәдән җил өрә. 3) Карлыгач ояны балчыктан ясый. 4) Рәшидә бауга кер элә. 5) Яшелчәләр кешегә бик файдалы. 6) Ботакларда бөреләр бик кечкенә әле. 7) Елгада боз кузгалды.

12. Алдагы күнегүдәге җөмләләрнең берсен сайлап, «Яз» темасына караган җөмләләрне дәвам итеп яз.

13. Сөйләм төрләрен әйт.

14. Текстны укы. Сорауларга җавап яз. Биремнәрне кайсы сөйләмгә кергәнен әйт.

Малай балыкка китте. Җайлырак, тынычрак урынны сайлап йөри торгач, ярдан читтәрәк ниндидер сәер тавыш колакка чалынды. Ләкин кем тавышы икәнен барып карамыйча танып булмады. Куак артында яраланган куян ята икән. Кемдер аңа аткан, тидергән, таба гына алмаган. Качып торырга да акылы җиткәндер инде. Ана куян булырга тиеш, чөнки бәләкәйрәк. Ә зуррагы таш сындай катып калган да аны каравыллый.

Әхсән Баяннан

15. Сылтама буенча «Туган тел» мультфильмын кереп кара. Туган тел турында әйтелгән фикерләрне телдән әйт һәм өч җөмлә яз.
https://yandex.ru/video/preview/7213648658121238708

16. Сүзләрне укы. Тартык аваздан башланган сүзләрне күчереп яз. Иртә, тәгәрмәч, чишмә, су, утын, әрекмән, болын, әкият, хәреф, машина.

17. Төшеп калган сүзләрне өстәп, белешмә төзе.
Авазлар без ... һәм ... .
Хәрефләрне без ... , ... һәм ... .
Файдалану өчен сүзләр: язабыз, ишетәбез, күрәбез.

18. Шигырьне укы. Сузык аваздан башланган юлларны тап.
Үсәсем килә
Безнең өйдә гөлләр күп.
Безнең өй дә гөлләр күк,
Әй күңелле, әй ямьле!
Өйдәге бу гөлләрне

Әби белән бергә без
Су сибеп үстерәбез.
Әби әйтә: “Гөлләр, ди,
Тыңлаусыз түгелләр, ди.
Көн дә су эчәләр, ди,
Шуңа зур үсәләр”, — ди.
Безнең өйдә гөлләр күп.
Минем дә шул гөлләр күк
Тизрәк үсәсем килә!
Әби эчәсем килә!

Рафис Корбан

19. Бер сузык аваз хәрефен алыштырып, яңа сүз яса.
Төн, ... , ... , ...
Көз, ... , ...
Саз, ... , ... , ... , ...

20. «Тартык һәм сузык авазлар ник дуслаша?» дигән темага 3–4 җөмлә төзе.

21. Рәсемдә нәрсә бирелгән? Татар әлифбасына гына кергән хәрефләрне һәм аларның авазларын әйт.





22. Төшеп калган хәрефләрне куеп, сүзләрне күчереп яз. Ул хәрефләр нинди авазларны белдерә?

Шә..әр, т..лке, ба..ана, ..арга, ..рдәк, та..ык, б..леш, я..гыр, ..имеш.

23. Сүзләрне күчереп яз. ң хәрефе сүзнең кайсы өлешендә килгән?

Таң, се-ңел, иң, а-ңа, ки-ңәш, миң.

24. Төшеп калган сүзләрне куеп, мәкальләрне укы. Ул сүзләрдә татар телендә генә булган авазларны әйт.

Китап — белем ... .
... эш таркалмас
Дусны табу ..., саклавы авыр.
Егет кешегә җитмеш төрле ... дә аз.

25. Текстны укы. Татар телендә генә кулланылган хәрефләр кергән сүзләрне күчереп яз, хәрефләрнең авазларын үрнәк нигезендә күрсәт.

Кыш урталары, һава салкын. Табигать инде ял итә. Җир йөзе кар юрганына төренеп, киңәеп, рәхәтләнеп йоклый. Ай яктысында кар бөртекләре җем-җем итеп ялтырап тора. Әнә ераста урман күренә. Авыл да, карга төренеп, тирән йокыга талган. Тәрәзәләрдә ут күренми. Тик авыл читендәрәк салынган бер йортта гына ут яна.

Садри Җәлал

Үрнәк: ял итә — ә – [ә], ...

26. Шигырьне укы. Истә калдыр. Хәтердән яз. Татар теленең үзенчәлекле авазларын белдергән хәрефләр астына сыз.

Әй минем апам һава
Фермада сыер сава.
Беркөн барып карадык,
Сыерларын санадык.

Мөхәммәт Садри

27. Бирелгән сүзләрне укы. Нәтиҗә яса.

аз — әз, ут — үт, ыс — эш, оч — өч, ил

28. Текстны укы. Калын әйтелешле сүзләрне генә күчереп яз. Сүзләрнең калын яки нечкә әйтелеше нәрсәгә бәйле?

Чукмар белән Тукмар

Бер әбинең ике әтәче булган. Аларның берсе ак, икенчесе кара булган. Әтәчләр күп вакытларын сугышып үткәрәләр икән.

Әби ак әтәчкә Чукмар, карасына Тукмар дип исем кушкан.

Чукмар чукырга бик оста, ә Тукмар бик нык тукмый икән.

Абдулла Алиштан

29. Сүзләр рәтен дәвам ит. Өч сүз белән җөмлә төзе.

Ат, ук, ... , … .

Әрем, үлән, ... , … .

30. Габдулла Тукай әкиятләренә ясалган рәсемнәрне кара. Әкият исемнәрен тап. Башта калын әйтелешле сузыклар, аннары нечкә әйтелешле сузыклар кергән әкият исемен язып куй.

31. Шигырьне укы. Калын әйтелешле сузыклар гына кергән юлларны тап. Светофор нинди киңәш бирә?

Светофорлы юлларда
Светофорлы юлларда
Миңа юлдаш төс — яшел,
Кызылга аяк атламыйм
Ялтыраса да яшел.

Сары төс кайчак алдата,
Аның сүнгәнен көтәм.
Артыннан яшел кабынса
Ашыкмыйм, кыю үтәм.

Вил Казыйханов

32. Нечкә әйтелешле сузыклар кергән Татарстан шәһәрләре исемнәрен яз.

33. Парлап бирелгән сүзләрне укы. Нәтиҗә яса.

Аз — әз, ут — үт, ыс — эш, оч — өч, ил.

34. Сүзләр рәтен дәвам ит. Дәвам итү тәртибен сыйныфташларыңа аңлатып бир.

Ат ук, ... , ...

Әрем, үлән, ..., ...

35. Шигырьне укы. Калын сузыклар гына кергән юлларны тап. Светофор нинди киңәш бирә?

Светофорның өч күзе
Урамнарны
Күзәтеп,
Ваемсызны
Кисәтеп,
Чатта тора

Светофор,
Сакта тора
Светофор.
Янып тора
Өч күзе.
Күреп тора
Ич безне,
Әйтеп тора
Өч сүзне:
– Кузгалма! — ди
Кызыл күз.
– Сабыр! — дия
Сары күз.
– Ярый! — дия
Яшел күз.
Без дә аңа
Карыйбыз.
Күзебезне
Алмыйбыз,
Ни әйткәнен
Аңлыйбыз:

– Кузгалма! — ди
Кызыл сүз.
– Сабыр! — дия
Сары сүз,
– Ярый! — дия
Яшел сүз!

Шәүкәт Галиев

36. Текстны укы. Күчереп язу кагыйдәсен искә төшер. Күчереп яз. Яңгырау тартыкларны ничек билгелисең?

Менә Мөбарәк урман буйлап бара. Тирә-якта кошлар сайрый. Кайдадыр саескан чакылдый. Тиеннәр сызгыра. Сукмак буйлап керпе йөри. Сукмак янында, бөгәрләнеп, елан йоклап ята. Бөтен урманны яңгыратып, тукран тукылдый.

Рабит Батулладан

37. Күп нокталар урынына саңгырау тартыклар өстәп, сүзләр яса.

А.. , а.. .
У.. , у.. .
Ка.. , ка.. .

38. Рәсемдәге кошларның исемнәрен әйт. Алар нинди тартыктан башлана? Бу кошлар турында нинди әсәрләр беләсез? Ул әсәрләрнең исеме нинди аваздан башлана?

39. Җөмләләрне укы. Яңгырау тартыктан башланган сүзләрне беренче баганага, саңгырау тартыктан башланган сүзләрне икенче баганага яз.

1. Күкне болыт каплады.
2. Галия дәфтәренә матур итеп яза.
3. Сания белән Зөһрә — тырыш кызлар.
4. Алан матур чәчәкләргә күмелде.
5. Атна исемнәрен түбәндәге тәр-типтә язып куй.

Яңгырау тартыктан башланган: ... ,
Саңгырау тартыктан башланган: ... ,

40. Бирелгән тартыкларны күзәт, нәтиҗә яса.

1. [б]–[п], [в]–[ф], [г]–[к], [µ]–[№], [д]–[т], [ж]–[ш], [җ]–[ч], [з]–[с].
[л], [р], [м], [н], [ң], [й], [х], [h], [ц], [щ], [w].
2. Артык сүзләрне тап. Ни өчен артык?

1) йөзек, мичкә, бәлеш, нур
2) хат, боз, цирк, һәйкәл, щётка

41. Сүзләрне парлап яз, парлы тартыкларны тап. Бер пар сүзне кулланып, җөмлә төзе.

җиләк — чиләк	гөл — ...
бәке — ...	зирәк — ...
зал — ...	дары — ...

42. Текстны укы. Башта парлы тартыктан башланган сүзләрне, аннары парсыз тартыктан башланган сүзләрне күчереп яз.

Камил нарат ботагы өстенә утырган тиенне күреп алды. Аның койрыгы гәүдәсеннән дә зур. Тиен, җитезлеген Камилгә күрсәтергә теләгәндәй, ботактан ботакка сикереп уйнады. Аның кыланмышларын күзәтеп тору кызык иде.

Роза Хафизовадан

43. «Шалкан» әкиятен исеңә төшер. Парсыз тартыктан башланган геройның исемен яз. Әкиятне дәвам ит.

44. Шигырьне укы. Я, ю,е хәрефләре кергән сүзләрне транскрипциядә яз.

Яңа ел ник картая?
Яшен яшәгән инде,
Эшен эшләгән инде,
Юллары бетеп бара…
Иске ел китеп бара.
Бабай булган — сакалы
Биленә җитеп бара…
Иске китсә моңаеп,
Яңа килә елмаеп —
Яшисе яше алда,
Юл чыккан яңа гына,
Ул әле бала гына.

Шәүкәт Галиев

45. Ребусны чиш. Сүздә аваз һәм хәреф санын эйт.



46. Файдалану өчен сүзләрне кулланып текстны укы. Соңгы өч җөмләне күчереп яз. Ике аваз кушылмасыннан торган хәреф кергән сүзләрнең астына сыз.

Беркөнне кызлар шуган ... музыка тавышы ... . Кызлар алар безнең кебек күлне әйләнеп шумыйлар. Ә икәүләп-өчәүләп җитәкләшәләр дә күлнең бер читендә бәләкәй алка ... әкрен генә әйләнәләр. Араларыннан берсе абынып ... , бөтен көтүләре белән сөрлегеп китәләр. Аннары кызыктан чырык-чырык көлешәләр. Малайлар да тик тормыйлар. Йә ... бәрелеп киткән булалар, йә ... асларына чыбык ташлап ... абындыралар.

Tahир Нәбиуллин

Файдалану өчен сүзләр: ясап, якта, егылса, ялгыш, юри, аяк, яңгырады.

47. Мәкальләрне укы, мәгънәсен аңлат. Транскрипциядә бирелгән сүзләрне хәрефләр белән күчереп яз.

[с ы й ы р ч ы қ] диңгез артына китсә дә, үз туган [о й а с ы н а] кайта.

Батыр ут булыр,
Куркак [й у қ] булыр.

48. Табышмакның җавабын тап. Аның турында өч җөмлә төзеп яз.
Күктән килде, җиргә инде.

49. Киңәшләрне дәвам ит. Я, ю, е хәрефләренең кушымчаларын әйт.
Яшелчәләр кешегә бик файдалы. Яшелчәләрне юып ашагыз ...

1.Күп нокталар урынына төшеп калган сүзләрне өстәп, җөмләләрне күчереп яз.

1.Балалар бакчасында ягымлы ... апалар эшли. 2. Җылы ... үзенең нурларын сибә. 3. ... аша басма салдылар. 4. Нәсимә ... хәбәр китерде. 5. Ул аны ... генә үчекли иде.

Ф а й д а л а н у ө ч е н с ү з л ә р: *кояш, юри, елга, тәрбияче, сөенечле.*

50. Рәсемне кара. Табышмакларның җаваплары тап.

51. Кош түгел оча,
Ябалактан курка,
Чикләвекне ярата,
Сызгырса, урманны яңгырата. (...)
Курыккан да курыккан,
Курыкмаганнан да курыккан,
Күләгәсеннән дә курыккан. (...)
Сорыдыр үзе,
Үткендер теше. (...)

52. Сүзләрне транскрипцияләп яз. Аларда ничә аваз һәм ничә хәреф бар?
егет, көянтә, юрган

53. Сүзләрдән җөмләләр төзеп яз. **Я, ю, е** хәрефе кергән сүзләрне үрнәк буенча тикшер.

1) куе, Татарстанда, урманнар, күп
2) яши, анда, җәнлекләр
3) бүре, безнең, очрый, аю, урманнарда

Ү р н ә к. *Куян* — [№ у й а н], ...

[к], [й], [н] — тартыклар;
[к] — парлы саңгырау тартык;

[й] , [н] — парсыз яңгырау тартыклар;
[у] , [а] — калын сузыклар.
Бу сүз дүрт хәрефтән тора: к, у, я, н.
Бу — ике иҗекле, калын әйтелешле сүз.

54. Транскрипциягә туры килгән сүзләрне яз.

[йә]	[йы]	[йү]
...	...	...
...	...	...
...	...	...

55. Шигырьне укы. **Я, ю, е** хәрефләре кергән сүзләрне транскрипциялә.

Яңа ел ник картая?
Яшен яшәгән инде,
Эшен эшләгән инде,
Юллары бетеп бара...
Иске ел китеп бара.
Бабай булган — сакалы
Биленә җитеп бара...
Иске китсә, моңаеп,
Яңа килә, елмаеп:
Яшисе яше алда,
Юл чыккан яңа гына,
Ул әле бала гына.

Шәүкәт Галиев

Үрнәк: Яшен — [йәшэн]; ... .

56. Файдалану өчен сүзләрне кулланып, текстны укы. Соңгы 3 җөмләне күчереп яз. Ике аваз кушылмасыннан торган хәреф кергән сүзләрнең астына сыз.

Беркөнне кызлар шуган ... музыка тавышы ... . Кызлар алар, безнең кебек, күлне әйләнеп шумыйлар. Икәүләп-өчәүләп җитәкләшәләр дә, күлнең бер читендә бәләкәй алка ... , әкрен генә әйләнәләр. Араларыннан берсе абынып ... , бөтен көтүләре белән сөрлегеп китәләр. Аннары, кызык табып, чырык-чырык көлешәләр. Малайлар да тик тормыйлар. Я ... бәрелеп киткән булалар, я, ... асларына чыбык ташлап, ... абындыралар.

Tahир Нәбиуллиннан

Файдалану өчен сүзләр: ясап, якта, егылса, ялгыш, юри, аяк, яңгырады.

57. Мәкальләрне укы, мәгънәсен аңлат. Тарнсрипциядә бирелгән сүзләрне хәрефләр белән күчереп яз.

* [сыйырчык], диңгез артына китсә дә, үз туган [ойасына] кайта.

* Батыр ут булыр,

Куркак [йук] булыр.

58. Киңәшләрне дәвам ит. **Я, ю, е** хәрефләренең кушымчаларын әйт.

Яшелчәләр кешегә бик файдалы. Яшелчәләрне әйбәтләп юыгыз...

59. Аваз белдерми торган хәрефләрне әйт. Алар нәрсәне белдерә?

Кагыйдәне бер-берегезгә сөйләгез.

ь (нечкәлек билгесе):

1) тартык авазның нечкә әйтелешен;

2) иҗекнең нечкә әйтелешен;

3) аеруны белдерә.

ъ (калынлык билгесе):

1) [К], [г] авазларының калын әйтелешен;

2) аеруны белдерә.

60. Сүзләрне укы. ь һәм ъ хәрефләренең нәрсә белдерүен әйт.

Яшь, пакь, ямьле, мәкаль, сәгать, табигать.

Нәкъ, шәфәкъ, вәгъдә, Тәгъзимә.

61. Текстны күчереп яз, **ь** хәрефе кергән сүзләрнең астына сыз. Бу хәрефнең нәрсә белдерүен аңлат.

Әсгать белән Тәлгать мәктәп бакчасында яшелчә үстерделәр. Мул уңыш алдылар. Мәктәптәге уңыш бәйрәмендә аларны альбом белән бүләкләделәр.

62. Күп нокталар урынына файдалану өчен бирелгән сүзләрне куеп, җөмләләрне укы. Әдәп-әхлак турындагы җөмләне күчереп яз.

1. Муса Җәлил — патриот- ... .

2. ... бирдеңме — үтә.

3. Ул ... ... уртасында торып чыгып китте.

4. ... җир бораулый.

Файдалану өчен сүзләр: *спектакльнең, шагыйрь, табигать, нефтьче, вәгъдә, нәкъ.*

63. Табышмакларның җавапларын рәсемнән эзләп тап һ иҗекләргә бүлеп яз.

* Башы бер, күзе унике.
* Ак ялан.
Ак яланда эз калган,
Эз өстендә сүз калган.
* Бите ак, күзе кара,
Бәйрәмнәрдә кызара.
Әйләнеп чыкса, шар ясый.

64. Бирелгән хәрефләрне күзәтеп, нәтиҗә яса.

А а а
Ә ә ә
Б б бэ
В в вэ
Г г гэ
Д д дэ
Е е йы/йэ
Ё ё йо
Ж ж жэ
Җ җ җэ
З з зэ
И и и
Й й кыска и
К к ка
Л л эль
Мм эм
Н н эн
ң эң
О о о
Ө ө ө
П п пэ
Р р эр
С с эс
Т т тэ
У у у
Ү ү ү
Ф ф эф
Х х ха
Һ һ һэ
Ц ц цэ

Ч ч чэ
Ш ш ша
Щ щ ща
ъ калынлык һәм аеру билгесе
Ы ы ы
ь нечкәлек һәм аеру билгесе
Э э э
Ю ю йу/йү
Я я йа/йә

Татар алфавитында ничә хәреф?
Хәрефләр ни өчен кирәк?
Аваз белдерми торган ике хәрефне әйт.

65. Укы. Язучыларның фамилияләрен алфавит тәртибендә яз.

Ләбибә Ихсанова, Әминә Бикчәнтәева, Габдулла Тукай, Абдулла Алиш, Муса Җәлил, Шәүкәт Галиев, Разил Вәлиев, Ләбиб Лерон

66. Әкият геройларын кара, алфавит тәртибендә яз. Биремне башкару тәртибен партадашына аңлат.



67. Әкиятләргә иллюстрацияләрне кара. Алар кайсы әкияттән? Җаваптагы сүзләрнең беренче хәрефе алфавитта ничәнче булып килгән?



68. Текстны укы. ё хәрефе турында нинди кызыклы мәгълүмат белдең?

Алфавитта һәр хәрефнең тарихы бар. Ә иң кызыгы — ё хәрефенең тугын көне бар. Ул моннан 238 ел элек туган. Россиянең биш шәһәрендә Мәскәү, Чиләбе, Пермь, Ульяновск, Чувашиядә ё хәрефенә һәйкәлләр куелган.

(www. znanio.ru сайтыннан)

69. Текстны укы. Текстның мәгънәсен төгәл аңларга нәрсә ярдәм итте?

Яз килүе һәр тарафта сизелә. Язгы урман үзенең төсен үзгәртте. Ул ак челтәр шәлен салды. Агачларда бөреләр уянды.

70. Сүзләрне укы. Сүзләргә басым куй.

китап, курчак, кемгә, нишли

борчак, нәрсәнең, төтен, кая

71. *Алма* сүзендәге басымга игътибар итеп, җөмләләрне укы.

Быел алма` күп булды.

Мансур, син тупны а`лма.

Сания алма` ашый.

Мөслим, син алма` а`лма.

72. Сүзләрне түбәндәге төркемнәр буенча яз.

Басым беренче иҗеккә төшә: ... ,

Басым урта иҗеккә төшә: ... ,

Басым соңгы иҗеккә төшә: ... ,

кайчы, чөнки, унбер, автобус, рәсем, кайсы, трактор, республика, татарча

73. Җөмләләрне рәсем эчтәлеге буенча укы. Һәр җөмләдәге *басма* сүзенә басым куй.

1. — Энҗе, суга басма.
2. Елга аша басма салганнар.

74. *Ярма* сүзенә басымны беренче һәм икенче иҗекләргә куеп, җөмләләр уйла.

75. Сүзләрне укы. Сүзләргә басым куй.

Китап, курчак, кемгә, нишли?

76. “Алма” сүзендәге басымга игътибар итеп, җөмләләрне укы.

Быел алма күп булды.

Мансур, син тупны алма.

77. Сүзләрне түбәндәге төркемнәр буенча яз.

Басымы беренче иҗектә:

Басымы урта иҗектә:

Басымы соңгы иҗектә:

Кайчы, чөнки, унбер, автобус, рәсем, кайсы, трактор, республика, татарча.

78. Җөмләләрне күчереп яз. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә басым куй.

Илсур Сабантуйда **батыр** калды.

Этне үзегезгә ияртмәгез, суга **батыр.**

Азат башына **кими.**

Елгада су **кими** башлады.

79. Сүзләрне укы. Сүздә иҗек санын билгелә.


Дус, энә, очыргыч.

80. Рәсемнәрдә нәрсәләр күрсәтелгән? Уртак иҗекне тап.

81. Рәсемнәрне сүз белән әйт. Уртак иҗекне тап.







82. Сүзләрне күчереп яз, иҗекләргә бүл.

кыяр, кәбестә, чөгендер, авыл, суган, кишер, шалкан, кабак

Үрнәк. *Бәрәңге, ...*

83. Мәкальләрне укы. Мәгънәләрен аңлат. Башта бер, аннары ике иҗекле сүзләрне күчереп яз. Ике иҗекле сүзләрдә басымлы иҗекнең астына сыз.

Эше барның ашы бар.

Җәй эшләсәң, кыш ашарсың.

84. Иҗекләрдән сүзләр төзеп яз.
Да, ук, ту, са

85. Сүзләрдә иҗек санын үстер.
кар
, ,
аш

86. Төшеп калган хәрефләрне өстәп, сүзләрне укы.
к .. зг .. , ..тәрг .. ч , к .. з , б .. так , т .. т .. н , б .. л .. н , с .. лг ..

87. Нәрсә ул алфавит?
Татар алфавитында ничә хәреф?

88. Бирелгән сүзләрдән икешәр сүз яса, басымнарын билгелә.
карчыга, күлмәк, балавыз

89. Табышмакны укы, җавабын тап, авазларын һәм хәрефләрен әйт.
Яз килсә — киенә,
Көз килсә — чишенә.

90. Сүзләрне укы, үзенчәлеген әйт.
Су, сум, сары, суган, Солтан.

91. Бер авазы белән аерылган сүз өстәп яз.
Каш — ..., бал —..., әни —..., бала —..., җир —..., көз —..., сан —..., көн —....

92. Шигырьне укы. Бер генә авазы белән аерылган сүзләрне күчереп яз.
Әбиләрдә кунакта.
Коймагы да коймагы,
Агып тора каймагы.
Табада пешеп тора,
Табынга төшеп тора.
Кайнар!- ялан кул тотма.
Тәмле!- телеңне йотма.
Син телең йотсаң, Нәбирә,
Кем рәхмәт әйтер әбигә.

Шәүкәт Галиев

93. Бирелгән сүзләргә хәреф өстәп яңа сүз ясап яз. Аваз санын әйт.
Аш — таш, ат —..., порт — ..., алан —..., иләк—... .

94. Шигырьне укы, үзгәргән сүзгә фонетик анализ яса.

Бүре диеп язган идем,
Куркыныч булып китте
“К” хәрефе өстәдем дә
Бүрене бүрек иттем.

Рафис Корбанов

95. Г, к, в хәрефләренең авазларын әйт.

96. Текстны укы. К, г хәрефләре кергән сүзләрне күчереп яз, авазларын үрнәк буенча күрсәт.

97. Текстны укы. **Г** хәрефе кергән сүзләрне күчереп яз, авазын күрсәт.

Кичке эңгер-меңгер вакыт. Авыл башында чирәмлектә уйнап йөрүче малайлар тавышыннан тирә-юнь гөж килә.

Малайлар тегермәнгә таба атладылар. Башкалар артта калды. Хәзер инде бары алга атларга. Туктарга һич ярамый. Мансур да, Зирәк тә үз уйларына бирелгән. Ә каршыда, серле булып, иске тегермән күренә. Ул әкияттә сөйләнә торган сарайларны хәтерләтә. Тик бераз гына авыша төшкән...

Рафис Гыйззәтуллиннан

Үрнәк: эңгер-меңгер — г [г].

98. Рәсемнәр кайсы әкияткә туры килә? Әкият исемнәрен транскрипциядә күрсәт.



99. Рәсемнәрне сүзләр белән яз. Нинди охшашлык бар?



100. Сүзләрне укы, иҗекләргә бүл, в хәрефенең астына сыз, нәтиҗә яса.
Вакыт, савыт, вак, тавыш, авыл, гөрләвек, һава, Кәримов, Әминов.

Рәсемнәр буенча җөмләләр яз. Рәсемнәр кайсы әкияткә туры килә? Әкиятне тулысынча укып чык.






Төлке казны тота.
Каз төлкедән биергә сорый.
Каз бии, төлке көлә.
Каз канатларын җилпеп очып китә.

101. Транскрипциядә бирелгән сүзләрне хәрефләр белән күчереп яз.
[wак], [wакыт], [wәли], [awыл], [ваза], [дawыл], [вагон], [дәwа]

102. Һәр төркемгә сүзләр уйлап яз.
гөл тургай газета
... ...
... ...
... ...

103. Шигырне укы. Авазлар һәм аваз тезмәләренең әйтелешенә, сүз басымына игътибар ит.

Паровоз
Вагоннар
җырлап чаба:
Ах-ах-ух!
Ах-ах-ух

Свисток
яңгырап китә:
Ту-ту-ту!
Ту-ту-ту!

Тавыш
Еракка җитә:
Уу-уу-уу!
Уу-уу-уу!
Муса Җәлил

104. Текстны укы. Сүз басымын күзәт, нәтиҗә яса.
Муйнак белән очрашуны мин кызыксынып көттем. Ничек икән ул этнең зиһене?

Муйнак мине ерактан ук төсмерләде. Мине күрүгә, куанычын эченә сыйдыра алмыйча, шатланып өреп җибәрде. Аннары, чиный-чиный дүрт аяклап, туптай сикерергә кереште.

Гомәр Бәшировтан

105. Сүзләр рәтен укы. Сүзләргә басым куй, нәтиҗә яса.
Нинди? Кайчан? Ничек? Нигә?
Бармадым, килегез, җырлагыз, укыгыз.

106. Сүзләр рәтен дәвам итеп яз..
Баз, каз, …, …, … .
Тал, тар, …, …, … .

107. Шигырьне укы. Хаталы сүзләрне тап һәм төзәтеп яз. Шул сүзләргә басым куй.

Казышу

Әти-әни тирләп бешкән,
Карап торам кызганып.
Алар түтәл казып йөри.
Күлмәк җиңен зызганып.

Ә абый өйдән дә шыкмый,
Ярдәм итми аз гына.
Ул мөһим эш башкарам дип,
Компьютерда газына... *Мөнир Вафин*

108. Алдагы күнегүне малайга киңәш итеп яз. Сүзләрдә басым куй.

109. Җөмләләрне күчереп яз. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә басым куй.
Илсур Сабантуйда **батыр** калды.
Этне үзегезгә ияртмәгез, суга **батыр.**
Азат башына **кими.**
Елгада су **кими** башлады.

110. Җөмләләрне күчереп яз. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә басым куй.
1. Бу җөмлә рәсемгә туры **килми.**
2. Ул безгә күптәннән **килми** инде.

3. Азат башына **кими.**

4. Елгада су **кими** башлады.

111. Текстны укы. Күчереп яз. Текстта хаталарның (чуалтмышларның) астына сыз. Бер авазы белән аерылган сүзләрне сүзләрне түгәрәк эченә ал.

Борын-борын заманда,
Әти дә тумаганда,
Киттек урманга,
Җиләк җыярга.
Гыйнвар ае иде,
Җыйдык күп җиләк,
Булды бер чиләк.
Алып кайтырга
Җиктек бер ишәк.

112. Сүзләрне укы. «Мәктәп» темасына караган сүз-ләрне күчереп яз.

яз, дәрес, китап, укытучы, урам, укучылар, кыңгырау, пенал, каләм, курчак, дәфтәр, бетергеч

113. Сүзләрне һәм аларның аңлатмасын укы.

Башлык — баш киеме.	
Гөбәдия — татар халкының милли ризыгы.	
Дәреслек — уку-укыту эшендә кулланыла торган китап.	

114. Табышмакның җавабын тап. Ул сүз турында бирелгән схема буенча сөйлә.

Лампа түгел — яктырта,
Мич түгел — җылыта.
Ничә иҗек? — ... .
Ничә хәреф? — ... .
Ничә аваз? — ... .
Ничек әйтелә (калын яки нечкә)? — ... .

115. Рәсемне кара, җөмләләрне укы. Ни өчен *песи* һәм *мәче* сүзләре кулланылган?



1. Песи тычкан тота. 2. Мәче тычкан тота.

5. 5 авазлы, 4 хәрефле сүзләрне сайлап яз.

кояш, урман, яшен, чәчәк, язгы, быел, урам, агач, яшел, юлчы

116. Сүз турында нәрсәләр белдең?

117. «Өй» сүзен икенче сүз белән әйт.

118. «Читек» сүзенең мәгънәсен аңлат, аваз һәм хәреф санын билгелә.

119. Сүзләрне укы. Алар нәрсәне белдерә?
Чиләк, тычкан, кырмыска, имән, гөлҗимеш, көзге, чәйнек, бүрек, бөркет, кеше.

120. Сүзләрне төркемләп яз.

Төзүче, арыслан, юкә, тәлинкә, куян, кашык, әби, табиб, елан, чиләк, ромашка, күгәрчен, әрем, малай, кузгалак, чүкеч.

Кешеләрне белдергән:

Хайваннарны белдергән:

Үсемлекләрне белдергән:

Әйберләрне белдергән:

121. Текстны укы. Кешеләрне белдергән сүзләрне күчереп яз.

Мөниргә әтисе өр-яңа велосипед алып кайтты. Мөнир велосипедын алды да урамга чыкты. Аның тирәсенә шундук иптәш малайлары җыелды.

— Мөнир, велосипедыңны миңа да бирерсең әле, йөреп карарга, — диде Илдус.

Мөнир велосипедын би-рер-гә теләмәде. Аның үз әйберенә беркемне дә кагылдырасы килми иде.

Нурихан Фәттахтан

— Мөнир сүзе җөмлә уртасында килсә, нинди хәрефтән (баш, юл) язарсың?

— Кем? соравына җавап биргән сүзләргә исем бир.

122. Сүзләрне төркемләп яз.

төзүче, арыслан, юкә, тәлинкә, куян, кашык, әби, табиб, елан, пычак, ромашка, күгәрчен, әрем, малай, кузгалак, чүкеч

Кешеләрне белдергән сүзләр: ... ,

Хайваннарны белдергән сүзләр: ... ,

Үсемлекләрне белдергән сүзләр: ... ,

Предметларны белдергән сүзләр: ... ,

123. Сүзләрне укы, артык сүзне тап. Алар нәрсәне белдерә?
карлыган, гөлҗимеш, балан, бабай, көчле, такта, таяк, болын

124. Һөнәрне белдергән сүзләр уйлап яз.

125. Шигырьне укы. Калын хәрефләр белән бирелгән сүзләр нәрсәне белдерә?

Чишмә

Челтер-челтер чишмә ага,
Көмеш төсле сулары.
Су өстендә җем-җем итә
Көнне алтын нурлары.
Тау астында чишмәбез, -
Су алырга төшәбез.
Татлы суын без аның
Бик яратып эчәбез.

Әхмәт Исхак

126. Рәсемдә бирелгән предметларның билгеләрен белдергән сүзләр уйлап яз.

127. Текстны укы. Предметның билгесен белдергән сүзләрне тап.

Ак Әтәч — затлы Әтәч

Яшәгән, ди, булган, ди, бик кыланчык һәм мактанчык бер Әтәч. Кыланырлыгы да бар икән, ди, үзенең. Гәүдәсе зур, канатлары көчле, аяклары тимердәй нык, ди. Башындагы кәләпүше ата үрдәкнеке сыман карасу-яшькелт төстә, елкылдап тора, ди.

Роза Хафизовадан

128. Күп нокталар урынына төшеп калган сүзләрне куеп яз.

Тай

Әни мине йокыдан ... тавыш белән уятты. Мин, торып, ишегалдына чыктым. Безнең ат ... тай алып кайткан иде. Тай үзе ... , аркасыннан ... тасма сузылган. ... аякларына ... оек кигән. Ул, ... , ... , ... аякларына басып, әнисен имә.

Гомәр Бәширов

Ф а й д а л а н у ө ч е н с ү з л ә р: *нечкә, җирән, йом--шак, ак, көрән, хәлсез, алгы, озын, кечкенә*.

129. Табышмакның җавабын тап һәм аның билгеләрен белдергән сүзләр уйлап яз. Ул сүзгә нинди соравына җавап җиргән сүзләр әйт.

Баш-аяксыз — буе бар,
Гәүдәсе юк — кулы бар. (…)

130. Сүзләрне бирелгән төркемнәргә яз. Үзең башкара ала торган гамәлләрне белдергән сүзләрне төркемнәргә яз.

чаба, яра, сикерә, оча, утырта, дәвалый, йөзә, юа
Эшне белдергән сүзләр: ... ,
Хәрәкәтне белдергән сүзләр: ... ,

131. Күп нокталар урынына предметның эшен, хәрәкәтен белдергән сүзләр уйлап яз.

Җил ... , кош ... , укытучы ... , тукран ... , төзүче ... , ат ... , балык ... , су ... , табиб ... , чәчәк ... .

132. Рәсемне кара. Тук-тук бабай белән Шуктуганның эш-хәрәкәтләрен белдергән сүзләрне әйт.

133. Абдулла Алишның «Сертотмас Үрдәк» әкиятендә Үрдәккә очраган җәнлекләрнең эшләрен белдергән сүзләрне язып куй.

134. Җөмләне укы. Җөмләдә һәр сүз нәрсәне атый? Җөмләдә сүзләр бер-берсенә ничек бәйләнә?

Балалар урманга бара.

135. Җөмләләрне укы. «Бүлмә» сүзенә күзәтү ясап, нәтиҗә чыгар. Нинди кушымчалар ялганган? Үзгәргән сүзләрне күчереп яз.

1) Безнең бүлмә өченче катта урнашкан.
2) Безнең сыйныф бүлмәсе якты.
3) Бүлмәдә өч тәрәзә бар.
4) Бүлмәнең тәрәзәләре зур.

136. «Бакча» сүзенә кушымчалар өстәп яз. Нинди кушымчалар ялгадың? Үзгәрә торган өлешнең астына сыз.

137. Сүзләрне үзгәртеп, җөмләләрне төзеп бетер.

1) Өй түбәсе.. тамчы.. тама.
2) Юллар.. сулар җыел.. .
3) Урман күгелҗем төс.. кер.. .
4) Көн.. җылынды, җылы яңгыр.. яуды.

138. Рәсемнән файдаланып, нокталар урынына тиешле кушымчаларны өстә.



Беркөнне Кызыл Калфак... әнисе сумса пешергән. Кыз... сумса... әбисенә илтергә кушкан.

Менә кыз урман буйлап барган. Аңа бүре очраган. Ул Кызыл Калфак... ашарга теләгән. Кызыл Калфак... урман буйлап чапкан. Ә Бүре ул арада тиз генә өенә кереп качкан.

«Кызыл Калфак» әкиятеннән

139. Әкият эчтәлегеннән чыгып, сорауларга җавап яз.
1) Кызны кем дип йөрткәннәр?
2) Әнисе кызга нинди эш куша?
3) Кыз кая китә?
4) Кыз кемне очрата?

140. Нәрсәне белдерүләренә карап, предметны тап.
Календарьда атнаның беренче көне.
Алмагачның җимеше.
Җәй ае.
Ачкыч белән бикләнү өчен эшләнгән җайланма, бикләвеч.









141. Сүзләрдән җөмләләр төзеп яз. Беренче җөмләне ахырында сорау куярлык итеп үзгәртеп яз.
1) баралар, балалар, балыкка
2) алар, елга, менә, буена, җиттеләр

3) кармакларын, генә, салдылар, әкрен, суга

142. Сүзләргә тиешле кушымчаларны өстәп яз.
Балалар урман... керпе күрде.
Резедә гөл... су сибә.
Малай... коеналар.

143. Җөмләләрне укы, күзәт, нәтиҗә яса.
Җәмилә бүген татар теле дәресендә бишле алды.
Укучылар каникулда Мәскәүгә бара.
Әминә дәресләрдән соң Айсылуның хәлен белергә керде.

144. Сүзләрнең үзгәрешен күзәт.
Нәтиҗә яса.
Яз, көн, җит.
Язгы көн.
Язгы көннәр җитте.

145. Җөмләләрне генә сайлап яз.
1) Табигатьтә яз билгеләре күренә башлады.
2) Ояны малайлар.
3) Елга буенда бала-чага күп иде.
4) Өй кыеклар сыерчык җилпенә.
5) Тау сыртында беренче чәчәкләр күренде.

146. Рәсем буенча җөмләләр төзе.

147. «Яз» темасына караган җөмләләрне табып укы.

1) Кызлар бергәләп рәсем төшерәләр. 2) Тәрәзәдән җил өрә. 3) Карлыгач ояны балчыктан ясый. 4) Без суган утыртырга түтәл ясадык. 5) Яшелчәләр һәм җиләк-җимешләр бик файдалы. 6) Ботакларда япь-яшь бөреләр күренде. 7) Өй кыекларында боз сөңгеләре асылынып тора.

148. Җөмлә чикләрен билгеләп, текстны күчереп яз.

Мәргән

Мәргән елга янына килде Ул елганың биек ярына утырды Каршы якта куаклар кыштырдады Мәргән шул якка карады Куак арасында зур гына аю күренде

Әхмәт Фәйзидән

149. Дәфтәрдә «Казан буенча кыскача экскурсия» маршрутын төзе. Һәр туктalышны партадашыңа аңлатырга әзерлән.

150. Укы һәм чагыштыр.

Бер әбинең бик кадерле әтәче белән көчеге булган. Ул аларны башка хайваннарга караганда артыграк яраткан. Чөнки әтәч аны йокысыннан уяткан. Көчек әбинең өен саклаган. Әтәч белән көчек үзләре дә бик дус яшәгәннәр.

Ишегалдында көчек калды.
Әтәч тавышына бар кеше уяна.

151. Текстны укы. Сорауларга җавап бир.

Татарстан Республикасының иң зур шәһәрләре — Казан һәм Яр Чаллы. Яр Чаллы Чулман елгасы буенда урнашкан. Аның даны ерак ларга таралган. Монда Россиянең иң эре заводларыннан берсе — КамАЗ — бөтен дөньяга танылган йөк машиналары ясала. Казан шәһәрендә самолётлар, вертолётлар, медицина җиһазлары, мех һәм тегү әйберләре җитештерелә.

Текстта сүз нәрсә турында бара?

Алар турында нәрсә хәбәр ителә?

152. Бирелгән җөмләләрдән текст төзе һәм исем уйла. Соңгы җөмләне күчереп яз. Татар телендәге үзенчәлекле авазларны белдергән хәрефләр астына сыз.

1) Беркөнне тавык йомырка салган.
2) Әби ватып караган, вата алмаган.
3) Бер бабай белән бер әби яшәгән, ди.
4) Йомырка тәгәрәп төшкән, урталайга ватылган да.
5) Аларның чуар тавыклары бар икән.
6) Нинди диген әле, гади йомырка түгел, алтын йомырка.
7) Бабай йомырканы ватып караган — вата алмаган.
8) Бер тычкан үтеп бара икән, йомыркага койрыгы тиеп киткән.

Рус халык әкиятеннән

153. Рәсемнәрне җөмләләр белән туры китереп укы. Җөмләләрне килеп чыккан тәртиптә яз. Нәрсә килеп чыкты? Фикереңне аңлат.




1.Энем ат була, мин дилбегә тотам.



2. Мин дилбегәне акрын гына тартам.



3. Без энем белән бик тату уйныйбыз.



4.Равил каты йөгерә, башын артка ата.

154. Текстны укы, сорауларга җавап бир. Текстка исем куй.

Имән. Әти сөйләгән имән! Кайчандыр моннан сугыш давылы узган. Илебез солдаты туган җиренең һәр адымы өчен канын түккән. Бу чокыр-чакырлар әнә шул сугыш эзләре. Алай гына түгел, җир-әнкәнең әле төзәлеп җитмәгән яралары бит болар. Әле алар һаман әргиләр, сыкрыйлардыр.

Газиз Набиуллин

— Малай имән белән ничек таныш?

— “Кайчандыр моннан сугыш давылы узган” дигән җөмләне ничек аңлыйсыз?

— Илебез солдатлары туган ил өчен ничек сугышкан?

— Сугыш булган җирне нәрсәләр хәтерләтә?

— Ул чокырларны нәрсәгә тиңлиләр?

— Сугышның каты булганын кайсы сүзләр күрсәтә?

— Текстка нинди исем биреп була? Ни өчен?(Имән, сугыш давылы, җир-әнкәнең яралары һ.б.)

155. “Зирәк карт” әкиятен искә төшер.Эчтәлеген күршеңә сөйлә.

156. Сорауга җавап бир. Нәрсә ул җөмлә?

157. Сүзләрдән җөмләләр төзе. Нәрсә килеп чыкты? Мәгънәсен аңлат.

1) Бер, туйдыра, язның, көне, ел.

2) Үлчә, бер, кат, җиде, кис, кат.

158. Текстны укы. Текстта нәрсә турында хәбәр ителә? Бу әсәргә капма-каршы нинди әсәрләр бар? Исемнәрен әйт.

Борын-борын заманда бер ярлы карт яшәгән, ди. Аның тимер балта-сыннан башка бер әйбере дә булмаган. Беркөнне көчле давыл чыккан. Карт басмадан чыкканда, балтасын төшереп югалткан. Һәм кычкырып елап җибәргән. Шулвакыт аның елавын балык ишеткән. Сәбәбен белгәч, аңа ал-тын балта биргән. Карт үз балтасы чыкканчы балык биргән балталарны алма-ган. Тугрылыгы өчен, балык картка өч балта биргән.

Сурия халык әкияте

159. Сүзләрнең бүленешен күзәт. Нәтиҗә яса.

Се – берке, себер – ке.

160. Сүзләрне юлдан юлга күчерерлек итеп сызыкча аша яз.

Бәрәңге, бияләй, вакыт, гомер, дөрес, дүшәмбе, көн, муен.

161. Сүзләрне укы. Юлдан юлга күчереп буламы? Ни өчен?

Оя, онык, аваз, авыз, авыл, шуа, юан, укы.

162. Сорауларга җавап бир.

Татарстан җире аша нинди елгалар ага?

Елга исемнәрен юлдан-юлга күчерерлек итеп сызыкча аша яз.

Алар нинди кагыйдәгә туры килә?

163. Текстны укы. Текстта сүз нәрсә турында бара? Ул нинди бәйрәм? Ка-лын хәрефләр белән бирелгән сүзләрне иҗекләргә һәм юлдан-юлга күчерер-лек итеп күчереп яз.

Кышын да үзенең яшеллеген җуймый торган **нарат агачы** астында бүген бәйрәм — **Сабан туе.** Зур мәйдан тирәли кунаклар тезелешеп утырган-нар. Һәммәсе дә үзенең һөнәрен, **осталыгын**, кыюлыгын күрсәтергә **ашыга.** Күбәләк — түгәрәк, канатларын **җилпеп,** оста җыры, матур биюләре белән кунакларның күңелләрен тапмакчы була.

«Әкиятләр илендә» җыентыгыннан

164. Сораулар буенча «Сабантуй бәйрәме» турында мәгълүмат җый. Сабан-туй сүзен юлдан-юлга күчерү тәртибен аңлат.

Сабантуй сүзе нәрсәне аңлата?

Аны кайчан бәйрәм итәләр?
Сабантуй булган урын ничек атала?
Сабантуйда була торган төп чаралар нинди?
Гаиләгездә Сабантуйга ничек әзерләнәләр?
Безнең Республикада әзерлек ничек бара? Бу турыда өлкәннәрдән сора.

165. Сүзләрне ике төркемгә бүлеп яз.

Соры, озын, бөре, болын, көзге, сөлге, көмеш, колын, мөгез, олы.

166. Рәсемнәрне сүз белән ата.





167. Шигырьне укы. **Ө, е** хәрефләре кергән сүзләрне күчереп яз. Саматның авыруы белән гөл шиңү арасындагы уртаклыкны тап. Һәр биремгә туры килгән дүртьюллыкны табып укы. о-ө хәрефләре кергән сүзләрне күчереп яз.

Гөл нигә шиңгән?
Бик эссе көннәрдә
Барсы су сорыйлар.
Сипмәсәң — шиңәләр,
Кибәләр, корыйлар.

Бакчада гөлләргә
Самат та сибә су.
Сипсә дә, гөлләре
Шиңәләр соң нигә?

Самат, бик әлсерәп,
Шул суны эчкән, ди,
Беркөнне, авырып,
Тамагы шешкән, ди.

Аңлаган Самат та,
Терелеп көч кергәч:
Үсми гөл эсседә,
Салкын су эчергәч... *Илдар Юзеев*

Эссе көндә гөлләргә су кирәк.
Су сибүнең нәтиҗәсе юк.
Салкын су гөлләргә зыянлы.

168. **О, ө** хәрефләре куергән яшелчә исемнәрен әйт. Энциклопедиядән берәр яшелчә турында мәгълүмат табып яз.

169. Исемнәрендә **о, ө** хәрефләре булган әкият геройларын яз.

Кошлар язын	Җөмләме? Ни өчен җөмлә түгел?
Кошлар язын кайталар.	Ә хәзер ни өчен җөмлә?

Җөмләдә нәрсә турында хәбәр ителә?
Нинди тавыш белән укыйбыз?
Җөмлә азагында нинди тыныш билгесе куябыз?

170. Текстны укы. Текстта ничә җөмлә икәнен билгелә. Җөмлә ахырында ни өчен нокта куелганын партадашыңа аңлат. Соңгы җөмләне күчереп яз.

Каен

Урманның иң сылу агачы — каен.

Ул — урманда хуҗабикә. Каеннар барлык төр урманнарда да үсә.

Башка агачлардан үзенең ак кәүсәсе, куе яфраклары белән аерылып тора. Каен — һәртөрле авыруга дәва.

Энциклопедиядән

171. Җөмлә ахырында нокта куелган җөмләләрне генә күчереп яз.

1) Бәйрәм бик күңелле узды
2) Шунда мин ояга күз салдым
3) — Оят түгелме сиңа, Аю
4) Гаҗәеп матур иде ул чәчәк
5) Ул агачта тукран тукылдый иде

172. Бирелгән җөмләләрдән текст төзе. Беренче һәм соңгы җөмләне күчереп яз.

Алма

1) Кыз озак итеп тәмле алмага карап торды.
2) Ул алма шулкадәр зур, шулкадәр тәмле, шулкадәр хуш исле иде.
3) Күп тә үтмәс, ул орлыклардан тагын да тәмлерәк, алмалар үсәр.
4) Бакчачы бабай Чулпанга түм-түгәрәк, кып-кызыл бер алма бирде.
5) Алар алманың вак төшләрен мәктәп бакчасына утырттылар.

6) Ләкин ул кызыл алманы ашарга ашыкмады.

7) Чулпан кулындагы алманы иң якын иптәшләре белән бүлешеп ашады.

Идрис Туктардан

173. Рәсем буенча текст төзе.



174. Сорауларга җавап яз.

1) Кошлар кайчан кайта?

2) Балалар кошларны ничек каршылыйлар?

3) Син кошлар турында ничек кайгыртасың?

175. Татармультфильм сайтына кереп, «Койрыклар» мультфильмын кара. Эчтәлеге буенча 4 җөмлә яз.

Җөмләләрне тиешле тавыш белән укы, нәтиҗә яса.

— Терем-теремкәй, теремдә кем яши?

— Ә син үзең кем буласың?

176. Текстны укы. Төшеп калган тыныш билгеләрен аңлат.

Әти рәсеме

Ник танымаска соң ... Әтием рәсеме бит! Газетага басканнар... Астына язганнарны укыгач та белдем...Яхшы эшли дип мактаганнар...Әтиемне шулай мактагач ничек шатланмыйсын инде! Әнием дә бик куанды...

Госман Бакиров

177. Җөмләне укы, сорауны белдергән җөмләләр төзеп яз.

Көрән аюлар кышка май җыялар.

178. Шигырьне укы. Кирәкле тыныш билгеләрен әйт. Сорау интонациясе тудырырга ярдәм иткән сүзне тап.

Бакчада

Исәнме, әй алмагач,

Моңсумы без булмагач
Яңгырларны эчкәнсең,
Зур-зур булып үскәнсең
Пешәме алмаларың
Пешкәннәрен аларның
Дүрт күз белән көтәбез
Булат белән икәү без

Марс Шабаев

179. Табышмакны укы, җавабын әйт. Сорау билгесенең ни өчен куелганын аңлат.

Яшел яфрак эченә
Энҗе чуклар эленгән.
Аңкып тора хуш исе,
Ничек үсеп өлгергән? (...) *Әминә Бикчәнтәева*

180. Габдулла Тукайның «Шүрәле» әкияте буенча сорау җөмләләр төзеп яз.

181. Шигырьне укы. Көчле тавыш белән укылган җөмләләрне тап.

Түрдән узыгыз

Ишек ачыла,
Ишек ябыла.
Ишегем ачык —
Түрдән үтегез!
Кайчан булмасын —
Рәхим итегез!

Кемнәр килсә дә —
Ишегем ачык.
Дус-ишләр килү —
Үзе бер шатлык.
Госман Садә

182. Төшеп калган тыныш билгесен куеп, күчереп яз.

Сез кем, дип сорыйсызмы
Күмәч пеөерүчеләр без
Кешеләрнең йөзләренә
Шатлык төшерүчеләр без

Равил Фәйзуллин

183. Текстны укы. Исем куй. Тыныш билгеләренең куелышын аңлат.

...Гомәр дә әләкче бит! Белми идегезмени? Һә-әй, ниниди генә әләкче әле! Шуңа да дүртенчеләрнең берсе дә яратмый аны. Яратмасалар да, класташлары ияләнде инде аңа. Ни хәл итәсең, тумыштан килгән гадәт шул!

Алмаз Гыймадиевтан

184. «Минем гаиләм» темасына җөмлә ахырында өндәү билгесе куела торган өч җөмлә яз.

185. Шигырьне укы. Ни өчен өндәү билгесе куелганын аңлат. Хәтердән яз. Партадашың белән тикшер.

Кычкыралар: Бер! Гол! Ура!
Молодец! О-кей!
Дер селкенә стадион.
Гөр килә хоккей!

Роберт Миңнуллин

186. Үзең караган мультфильмдагы әкият геройлары турында өндәү билгесе куела торган җөмләләр төзеп яз.

187. Шигырьне укы. Юлдан-юлга күчми торган сүзләрне күчереп яз.

Кызык инде бу бабай
Көн кояшлы булган чакта,
Марс йөри, сөенеп.
Әллә нигә шундый чакта
Бабай йөри, көенеп.

Бүген әнә яңгыр ява,
Ишегалды чылана,
Бөтен урам пычрана бит!
Бабай шуңа куана.

Яйгыр яугач, җир пычрана
(Бабай шуны уйламый),
Җир пычрангач, өс буяла,
Әни тышка чыгармый.

Клара Булатова

188. Мәкальләрне укы, мәгънәсен аңлат. Төшеп калган хәрефләрне өстәп күчереп яз. Ул хәрефләрнең язылышын үз-үзеңә сөйлә.

* Туры с...йләгән — к...тылган,
Ялганлаган — т...тылган.
* Һ...нәрле үлми, һ...нәрсез к...н күрми.

189. Шигырьне укы. Җөмлә ахырында тиешле тыныш билгесен әйт. Тыныш билгесенең куелышын аңлат.

Кунаклар

Без әзерлибез табын,
Китереп бөтен ягын.
Уртага куйдык чәчәк,
Чәчәк янына чәкчәк
Бавырсак һәм кош теле,
Ризыклар төрле-төрле:
Сумса, бәлеш, өчпочмак,
Гөбәдия һәм коймак
Һәркемгә чыгар өлеш:
Бар кыстыбый һәм бәлеш
Җитешегез, кунаклар
Кыстатмагыз, кунаклар
Өйгә кайтып китәргә
Ашыкмагыз, кунаклар
...Безнең осталыкка соң
Ышанмыйсың әллә син
Үзебез ясадык, дим,
Пластилиннан һәммәсен

Шәүкәт Галиев

190. Татар халык ризыклары исемнәрен кулланып, җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләре куярлык итеп, җөмләләр төзеп яз.

191. Шигырьне укы. Нинди сүзгә син игътибар иттең? Ул сүз турында нәрсә әйтерсең?

Рәхмәт — зур сүз

Әгәр сезгә бүләк бирсәләр,
рәхмәт әйтегез!
Әгәр сезне усал каздан якласалар,
рәхмәт диегез!
Сиңа юл өйрәтсәләр, рәхмәт әйт!
Сиңа «зур үс» дисәләр, рәхмәт әйт!
Рәхмәт әйтә белә әйбәт малай, әйбәт кыз.
Рәхмәт ул — әйбәт сүз, зур сүз, олы сүз.

Мәхмүт Газизов

192. Җөмләләрне укы. Алинә Артурдан ник гафу үтенде? «Гафу үтенү» сүзләре рәтен дәвам ит.

Безнең сыйныфка Мәскәү шәһәреннән яңа укучы килде. Аның исеме Артур иде. Артурга татар теле бик авыр бирелде. Мәскәүдә ул татар телен өйрәнмәгән. Алинә Артурга дәресләрдән соң булышырга вәгъдә бирде. Дәресләрдән соң Алинәгә әнисе шалтыратты. Ул аңа дәресләр бетүгә өйгә кайтырга кушты.

Алинә тиз генә җыенды да өенә кайтып китте, Артурга биргән вәгъдәсен онытты. Артур Алинәне көтеп озак утырды.

Иртән барысы да мәктәптә очраштылар. Алинә Артурны күрүгә вәгъдәсен искә төшерде һәм кызарып чыкты. Алинә уңайсызланып кына Артур яныны килде дә гафу үтенде.

Үрнәк: гафу ит, ...

193. Рәсемне кара. Сөйләү этикетын саклап, җөмләләр төзе.



194. Рәсемне кара. Бу рәсемгә нинди сүзләр туры килә?



195. Текстны укы. Камырбатырга узып баручы ни өчен бер сүз дә әйтмичә китеп барган? Таныш булмаган кешеләр белән ничек аралашалар? Камырбатырга киңәш яз.


Камырбатыр:

— Мин хәзер, сезнең янга килгәндә, шулкадәр ашыктым! Соңга калырмын дип, бер узып баручыга кычкырдым: «Әйт, сәгать ничә?», ә ул миңа усал итеп карады да бер сүз әйтмичә китеп барды.

1.Укытучы безгә, бүген сөйләшербез, тыңларбыз, мультфильм карарбыз, диде.

Нинди сөйләм турында сүз бара?

196. Рәсем буенча текст төзе. Сыйныфташларыңа сөйлә.



197. Сылтама буенча Шәүкәт Галиевның «Акыл теше кемгә чыга» шигырен тыңла. Баланың җавабына кемнәр, ничек җавап бирә? Бу нинди аралашу ситуациясенә керә?

https://zvukislov.ru/books/170744-sh-v-li-shuklygy/

198. «Тыңлагыз, радио сөйли!» дигән язмадан син нәрсә аңлыйсың? Син радиодан нинди тапшырулар тыңлаганың бар? Кайда? Кайчан?

198. Сылтама буенча «Каз белән аккош» мультфильмын кара. Зилант кем ул? Мультфильм алдыннан Зилант нәрсә турында сөйли? Мультфильм нәрсәгә өйрәтә? Телдән кемнәр аралаша?

https://yandex.ru/video/preview/4528215892701330868

199. «Шаян ТВ» телеканалының рәсми сайтына кереп, «Шаян балалар» тапшыруы турында чыгыш әзерлә.

200. Рәсемнәрне кара. Рәсемнәрдә аралашуның нинди төре күрсәтелгән?





201. Шигырьне укы. Шигырьдә ничә малай катнаша? Ничә профессия кешесе турында сүз бара? Үзең теләгән малайның сүзләрен сайлап, рольләргә бүлеп укырга әзерлән.

Малайлар сөйләшә

— Мин үскәч абый булам.
Аннары бабай булам!
— Ә мин, бабай булгач та,
Гел әйбәт малай булам!
— Мин үзем әти булам!
— Ә мин Дәү әти булам!
— Үскәч кем буласымны
Мин әле әйтми торам.
— Мин батыр солдат булам!
— Мин космонавт булам!
— Ә мин Третьяк булам!
Капкада сакта торам.
— Ә мин корыч коючы,
Чуен коручы булам!
— Мин күз буучы булам!
— Ә мин аучы булам да
Көн дә йөрим сунарга!
— Ә мин белмим, әнидән
Онытканмын сорарга.
— Ә мин бик озын булам,
Үсәм әле тагын да.
— Ә мин начальник булам,
— Йөрим «Волга»да гына!
— Ә мин кибетче булам!
— Ә мин бик көчле булам —
Әтием төсле булам!
— Мин комбайнчы булам!
Кырда иген урырга!
— Ә миңа әни, үскәч,
Куша КЕШЕ булырга!

Роберт Миңнуллин

— Ә хәзер чиратлап рольләргә бүлеп укыгыз, мин диктофонга яздырам.
— Тыңлагыз, үз тавышыгызга бәя бирегез.
Сунарга чыгу — ауга чыгу.

202. Алдагы шигырьдә соңгы ике юлны ничек аңлыйсың? Партадашың белән диалог төзе.

203. «Минем яраткан дәресем» темасына диалог төзе. Синнән алдагы партада утырган сыйныфташың белән диалогны рольләргә бүлеп укы.

204. Текстны укы. Текст эчтәлеге буенча диалог төзе.

Кирлемән

Безнең әтиләр, бабайлар заманында ук булган ул Кирлемән. Аны һәр буын кешеләре җиргә күмеп кенә тоталар. Әгәр ялгышып җир өстенә килеп чыкса, балаларны кирелеккә өйрәтә. Ул кешеләргә бик күп зыян сала.

Роза Хафизовадан

205. Роберт Миңнуллинның «Малайлар сөйләшә» шигырендә Третьяк кем ул? Аның турында сыйныфташларыңа мәгълүмат әзерлә.

206. Текстны укы. Рәсемне кара. Текст белән рәсем эчтәлеге турында фикереңне әйт.

	Мине әнием шифаханәдә эшли. Ул авыруларны дәвалый. Әнием үз эшен бик яратып, җаваплы башкара. Авырулар да аны яраталар.
	Алмаз белән Азат футбол уйнарга яраталар. Алар мәктәптә футбол түгәрәгенә йөриләр. Бүген дәрестән соң алар күрше мәктәп укучылары белән уйныйлар.
	Алинә рәсем төшерергә ярата. Буш вакытында табигатькә чыгып матур рәсемнәр ясый.

207. Табышмакларны укы. Җавабын тап. Табышмаларда нинди шөгыльләр турында сөйләнә? Шөгыльләрнең берсен сайлап хикәя төзе.

Әнием ак сәйләп тезеп
Чиккән яшел бәрхетне.
Ул үзем кебек бәләкәй,
Ә исеме ….
Җырлый-җырлый сәхнәләрдә
Аларның биер чагы.
Кызларга бик килешә
Башындагы ……

208. Текстны укы. Исемен аңлат. Йолдызлар исемен язып куй,Алар турында сөйлә.

Йолдызлар

Ә сез беләсезме без ничәү? Безбишәү. Бер кызык әйтсәм көлмәссезме? Без барыбыз да йолдыз исемле!Чыннан әйтәм.Менә бармакларымны бөгә-бөгә санап күрсәтим әле. Әтием Җидегән исемле.Сеңлем — Чулпан. Әбием — Зөһрә. Кемне оныттым? Үземнең Йолдыз икәнлегемне беләсез ич инде.

Шамил Рәкыйпов

209. Текстны укы. Сорауларга җавап бир?

Салих Сәйдашев яшьтән үк музыка белән кызыксынды. Ул балачакта ук гармунда уйный иде. Салих үзенең гармунда уйнавын чит кешегә күрсәтмәскә тырыша иде. Әнисе белән апасы да бу турында беркемгә дә әйтмәделәр.

Шиһап Әхмәровтан

— Салих Сәйдашев кем ул?
— Бала чакта аның нинди шөгыле була?
— Салих Сәйдашевның бу шөгыле турында башкалар беләме?
— Ни өчен?
— Кем музыка белән шөгыльләнә?
— Шул турыда сөйләгез.
—

210. Бирелгән хәрефләрдән башланган һөнәрләр әйт. «К» хәрефеннән башланган һөнәр турында хикәя төзе.

— А — агроном, ... , ...
— Б — ... , ...
— Г — ... , ...
— Д — ... , ...
— Ж — ... , ...
— З — ... , ...
— К — ... , ...
— Т — ... , ...
— У — ... , ...

211. Текстны укы. Файдалану өчен бирелгән җөмләне төшеп калган урынга куеп күчереп яз.Бу шөгыль нинди һөнәргә туры килә? Шул һөнәр турында хикәя яз.

Мин өйгә әтидән иртәрәк кайтам. Шуңа күрә аш та пешереп куярга туры килә иде. Ашны йә күп итәм, йә бик аз була. Кайвакыт аш бик тозлы була, кайчак тоз салырга бөтенләй онытып җибәрәм.

Абдулла Алиштан

Файдалану өчен: Чаманы белми алҗыдым.

212. Текстны укы. Ул уен турында хикәяләп сөйлә.

Ак, димә, кара, димә...

Балалар төзелешеп утыралар. Сорау бирүче санамыш ярдәмендә билгеләнә. Ул балаларга төрле сораулар бирә. Аңа җавап бирүче «ак», «кара», «әйе», «юк» димәскә тиеш. Башны түбән ияргә дә, көләргә дә ярамый. Сорау алучы, бер баланың каршысына басып, әйтергә ярамаган сүзләрне әйттерү өчен, юри сораулар бирә.

— Синең күлмәгең нинди?

— Кызыл.

— Синең аягыңда туфлимы?

— Итекләр.

— Төсе нинди?

Әгәр бала ялгышып әйтергә ярамаган сүзне әйтсә, ул бала сорау алучы була. Уенның кагыйдәсен шигырь юллары белән әйтеп, уенны дәвам итә.

«Ак» димә, «кара» димә,
Башыңны түбән имә.
«Әйе» димә, «юк» димә,
Көлмә, елмайма.

213. Рәсемнәрдә нинди уеннар күрсәтелгән? Син кайсы уенны уйнаганың бар? Шул уен турында партадашыңа сөйлә.

1 нче рәсем — Футбол уенын сурәтләгән.

2 нче рәсем — кызлар скакалка сикергән күренеш.

3 нче рәсем — түгәрәк кырында балалар, уртада бер бала бармак белән төртеп санаган күренеш.

214. Җәйге каникулда нәрсәләр белән шөгыльләнергә уйлыйсыз? Шул турыда хикәя яз, рәсем яса.

215. Сорауга җавап бир. Сөйләм этикеты турында сөйлә?

216. «Өч» сүзе кергән әкият геройларын кертеп, кечкенә хикәя төзе.

217. Текстны укы, сорауларга җавап бир.

218. Текстны укы, сорауларга җавап бир. Текстта нинди сөйләм этикеты кагыйдәләренә туры килгән сүз кулланыла?

Искәндәрнең авылда апасы бар. Әтисенең апасы. Җәй көне Искәндәр шунда берәр ай ял итә, авыл балалары белән уйный. Авылда чишмәләр бик күп. Һәр чишмә суының тәме төрлечә. Искәндәр шуларның аермасын сизә.

Ләкин иң күңеллесе ат абзарында. Анысына ул һәр көн йөри. Апасыннан бер-ике кисәк каткан ипи ала да атлар янына килә. Арата арасыннан әни атлар, бала атлар аңа башларын суза. Искәндәр ваклаган ипине уч төбенә куя да аларга бирә. Башта бала атка, аннан әнисенә. Бала атның да, әни атның да иреннәре төкле була. Ипи кисәген әвәләп алганда, ул төкләр Искәндәрнең уч төбен кытыклый. Искәндәр чырык-чырык көлә, ә атлар, пошкырып, аңа рәхмәт әйтәләр.

Мөхәммәт Мәһдиев

Искәндәр җәй көне кайда ял итә?
Чишмәләрнең тәме нинди?
Иң күңелле хәл кайда була?
Искәндәр атларны нәрсә белән сыйлый?
Атлар аңа ничек рәхмәт әйтә?

219. Сылтама буенча кереп, «Кәҗә белән сарык әкиятен» тыңла. Эчтәлеге буенча кыскача хикәя төзе.

https://tatkniga.ru/books/106362

220. Текстны күчереп яз. Саңгырау тартыклар астына сыз.

Иртә белән көн матур һәм кояшлы иде. Кинәт кара болыт күтәрелде. Йомшак кына яңгыр җиле исеп куйды. Бакчадагы агач яфраклары җәй исе аңкытып җилфердәштеләр. Шул арада көчле яңгыр коя башлады.

Гомәр Бәшировтан

221. Кроссвордны чишсәң, җавапта Габдулла Тукайның «Кызыклы шәкерт» шигырендәге эт кушаматын табарсың.

1) Йорт хайваны.
2) Ак кәүсәле матур агач.
3) Канаты бар — очмый,
Аягы юк — йөри.
4) Өй түбәсендә ярты ипи.

5) Кечкенә генә эт
Өрми дә, җибәрми дә.

222. Сүзләрдән җөмләләр төзе.
1) күлгә, җәен, тотарга, алар, балык, йөриләр
2) каникулны, көтәләр, сагынып, балалар
3) рәхәтләнеп, туп, мәйданчыгында, алар, спорт, тибәләр

223. Чәчәк исемнәрен алфавит тәртибендә яз.
роза, умырзая, ромашка, кашкарый, лилия

224. Рәсем буенча хикәя төзеп яз.
Бу рәсемдә елның кайсы фасылы сурәтләнгән?
Балалар кая килгәннәр?
Алар кемнәргә булыша?
Балалар ничек эшли?
Аларның кәефләре нинди?
Син җәйне кайда уздырасың?
Каникул сүзендә ничә аваз һәм хәреф бар?

225. Сүзләрнең мәгнәләрен аңлатып яз.Алардан икешәр сүз яса, басым куй.
Карчыга, күлмәк, балавыз.

226. Рәсемгә карап, бирелгән төркемнәргә сүзләр яз.
Предметны белдергән: ... .
Предметның эш хәрә кәтен белдергән: ... , ...
Предметның билгесен белдергән: ... , ... , ...

227. Җөмләне укы. Сүзләрне алфавит тәртибендә яз.
Безнең тәрәзә арасына кош оя ясаган.

228. Син нинди проект өстендә эшләдең? Проектны якла.
Проект өчен темалар
1) Татарстан — туган ягым.
2) Сабантуй бәйрәме.
3) Һөнәр сайлыйм.

ҮТКӘННӘРНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН ТЕСТЛАР

1. Җөмлә ...төзелә.
а) иҗекләрдән ә) сүзләдән б) хәрефләрдән

2. Кайсы сүз иҗеккә дөрес бүленгән?
а) уч-ак ә) уча-к б) у-чак

3. *дөнья* сүзендә ... аваз
а) биш
ә) дүрт
б) ике

4. Ике [о] авазы булган сүзне билгелә.
а) төлке ә) толып б) торна

5. Кайсы сүз янгырау тартык аваздан башлана?
а) чирәм ә) пәрдә б) җиләк

6. [w] авазы булган сүзне билгелә.
а) телевизор ә) тавыш б) вертолет

7. Нечкә әйтелешле сүзне билгелә.
а) йозак ә) йөзек б) йомран

8. Кайсы сүзнең беренче иҗегендә бер генә аваз?
а) дәрес ә) әлифба б) көзге

9. Басым беренче иҗеккә төшкән сүзне юилгелә.
а) тиен ә) кайчан б) китап

10. Дөрес язылган сүзне билгелә.
а) дөнья ә) көньяк б) ямле

УКУ ГРАМОТАЛЫЛЫГЫН ҮСТЕРҮ ӨСТЕНДӘ ЭШЛИБЕЗ

I СЫЙНЫФ

II яртыеллык

1 вариант

Текст № 1. Чебиләр

Безнең сары тавык бар. Ул чебиләр чыгара. Чебиләр бик матур. Алар да сары төстә. Мин чебиләргә яшел чирәм ашатам. Әни ярма сибә. Чебиләр тиз үсә. *(25 сүз) (“Мәгариф” журналы, 2000 нче ел, № 4)*

чеби — цыплёнок
чыгара — высиживает
чирәм = үлән — трава
ашата — кормит
ярма сибә — сыплет крупу

1 часть

При выполнении заданий этого раздела (1–5 задания), правильные ответы отметь кружочком.

1. Безнең нәрсә бар?

1) каз
2) песи
3) эт
4) тавык

2. Чебиләр нинди төстә?

1) ак
2) кара
3) сары
4) зәңгәр

3. Мин чебиләргә нәрсә ашатам?

1) ипи
2) ит
3) яшел чирәм
4) сөт

4. Әни чебиләргә нәрсә сибә?

1) ярма
2) ботка
3) алма
4) аш

5. Чебиләр ничек үсә?

1) әкрен
2) зур
3) тиз
4) матур

2 часть

При выполнении заданий этого раздела (6–8 задания), ответы напиши кратко.

6. Хикәяне кем сөйли?
Җавап:_____

7. Хикәядә нинди геройлар бар?
Җавап:_____

8. Чебиләрне кемнәр ашата?
Җавап:_____

3 часть

На данный вопрос ответь полным предложением.

9. Хикәдәге бала нинди? Аның турында яз.
Җавап:_____

II вариант

Текст № 2. Күл
Менә болын. Болында күл бар. Күл буе бик матур. Анда камышлар үсә. Күлдә үрдәкләр йөзә. Балык күп була. Күл буена малайлар балык тотарга йөриләр. (24 сүз)
болын — луг
күл буе — возле озера
балык тотарга — на рыбалку
(“Мәгариф” журналы, 2000 нче ел, № 4)

1 часть

При выполнении заданий этого раздела (1–5 задания), правильные ответы отметь кружочком.

1. Болында нәрсә бар?
1) чәчәкләр
2) куяннар
3) күл
4) агачлар

2. Күл янында нәрсәләр үсә?
1) агачлар
2) алмалар
3) чәчәкләр
4) камышлар

3. Күлдә нәрсәләр йөзә?

1) үрдәкләр
2) тавыклар
3) казлар
4) яфраклар

4. Күлгә кемнәр килә?

1) кызлар
2) әбиләр
3) апалар
4) малайлар

5. Малайлар күлгә нәрсәгә киләләр?

1) җиләккә
2) гөмбәгә
3) чәчәккә
4) балыкка

2 часть

При выполнении заданий этого раздела(6-8 задания),
ответы напиши кратко**.**

6. Күл кайда?

Җавап:_____

7. Камышлар кайда үсә?

Җавап:_____

8. Күлдә нәрсә күп була?

Җавап:_____

3 часть

На данный вопрос ответь полным предложением.

9. Күл турында яз.

Җавап:__
_____
_____

II СЫЙНЫФ
Кереш тикшерү

I вариант

Текст № 1. Әбиләргә кунакка
Безнең әби Чаллыда яши. Мин Саттар абый белән әбиләргә кунакка барам. Менә касса. Саттар абый билет ала. Китәр вакыт җитә. Әти безне автобуска утыртты. (24 сүз)

китәр вакыт — время ухода/ отъезда
утыртты — посадил
(“Мәгариф” журналы, 2000 нче ел, № 4)

1 часть

При выполнении заданий этого раздела (1–5 задания), правильные ответы отметь кружочком.

1. Безнең әби кайда яши?
1) авылда
2) дачада
3) Чаллыда
4) Казанда

2. Мин кем белән кунакка барам?
1) әни белән
2) дусларым белән
3) әби белән
4) Саттар абый белән

3. Саттар абый кассада нәрсә ала?
1) билет
2) лоторея
3) ашамлык
4) китап

4. Кунакка кемнәр бара?
1) малай белән абый
2) кыз белән абый
3) бала белән әти
4) бала белән абый

5. Алар Чаллыга нинди транспорт белән баралар?
1) машина
2) теплоход
3) поезд
4) автобус

2 часть

При выполнении заданий этого раздела (6–8 задания), ответы напиши кратко.

6. Кунакка ничә кеше бара?
Җавап:_____

7. Абыйның исеме ничек?
Җавап:_____

8. Алар нинди шәһәргә баралар?
Җавап:_____

3 часть

На данный вопрос ответь полным предложением.

9. Бала Саттар абый белән нишли?
Җавап:_____

II вариант

Текст № 2. Урман
Безнең авылга урман бик якын. Без урманга барабыз. Җәй көне урманда бик матур. Анда кошлар сайрый. Төрле төстәге чәчәкләр үсә. Безнең урманда җиләк бик күп. Без җиләккә йөрибез.(28 сүз)

якын — близко
сайрый — поёт (о птицах)
төрле төстәге — разного цвета
(“Мәгариф” журналы, 2000 нче ел, № 4)

1 часть

При выполнении заданий этого раздела (1–5 задания), правильные ответы отметь кружочком.

1. Без кая барабыз?
1) бакчага
2) авылга
3) урманга
4) урамга

2. Урманда кайчан бик матур?
1) җәй көне
2) иртән
3) кыш көне
4) һәрвакыт

3. Урманда кошлар нишли?
1) җырлый
2) сөйләшә
3) укый
4) сайрый

4. Урманда нинди чәчәкләр үсә?
1) сары
2) кара

3) кызыл
4) төрле төстәге

5. Кайда җиләк бик күп?

1) урманда
3) бакчада
2) урамда
4) кибеттә

2 часть

При выполнении заданий этого раздела (6–8 задания), ответы напиши кратко.

6. Безнең авыл нәрсәгә бик якын?

Җавап:_____

7. Кемнәр урманга бара?

Җавап:_____

8. ***Без ни өчен урманга барабыз?***

Җавап:_____

3 часть

На данный вопрос ответь полным предложением.

9. Урман нинди?

Җавап:_____

I ЯРТЫЕЛЛЫК

I вариант

Текст № 3. Шаянкай

Урман читендә төлке яшәгән. Аның Шаянкай һәм Хәйләкәр исемле балалары булган.

Бервакыт Шаянкай югалган. Әнисе аны көне буе эзләгән. Аңа Хәйләкәр дә ярдәм иткән. Алар Шаянкайны таба алмаганнар, өйләренә бик арып кайткан-нар. Шаянкай өйдә булып чыккан. Барысы да бик шатланганнар.(40 сүз)

урман читендә — на опушке леса
югалган — потерялся
таба алмаганнар — не смогли найти
арып кайтканнар — пришли уставшие
булып чыккан — оказалось

(“Мәгариф” журналы, 2004 нче ел, № 8)

1 бүлек

Әлеге бүлек биремнәрен эшләгәндә (... биремнәр) дөрес җавапны саннар янында түгәрәк эчендә күрсәт.

1)Урманда кем яшәгән?

1) төлке
2) аю
3) бүре
4) песи

2.Кем югалган ?

1) Шаянкай
2) Йомшаккай
3) Хәйләкәр
4) Төлкекәй

3.Шаянкайны кем эзләгән?

1) әнисе
2) әтисе
3) апасы
4) әбисе

4 Кем ярдәм иткән?

1) Хәйләкәр
2) әтисе
3) Йомшаккай
4) күрше

5.Шаянкай кайда булган?

1) авылда
2) шәһәрдә
3) өйдә
4) урманда

6.Барысы да нишләгәннәр?

1) уйнаганнар
2) шатланганнар
3) йоклаганнар
4) йөгергәннәр

2 бүлек

Бу бүлекнең биремнәрен эшләгәндә (... биремнәр) җавапларын кыскача яз.

7.Төлкенең балалары:

Җавап:_____

8.Бу әкиятме, хикәяме?

Җавап:_____

3 нче бүлек

Түбәндәге биремдә сорауга җавапны тулы җөмлә белән яз

9.Геройлар турында яз.

Җавап:_____

II вариант

Текст № 4. Кар бабай

Көн җепшек иде. Балалар кар бабай ясадылар. Кечкенә Ира да булышты. Ул өйдән кишер алып чыкты.Аны борын итеп куйдылар. Айдар күзләргә күмер куйды. Кар бабайның кулына себерке тоттырдылар. Кич булды,балалар өйгә киттеләр. Ира гына китмәде. Ул кардан кечкенә эт ясады. (41сүз)

Җепшек — мокрый
Күмер — уголь
Себерке — метла
Алып чыкты — вынес

1 часть

При выполнении заданий этого раздела (1–6 задания),
правильные ответы отметь кружочком.

1. Көн нинди?

1) җепшек
2) буранлы
3) салкын
4) җылы

2.Балалар нәрсә ясады?

1) Кар бабай
2) Кыш бабай
3) Кар кызы
4) Суык бабай

3.Кишерне кем алып чыкты?

1) Ира
2) малай
3) Айдар
4) Марат

4.Ира нәрсә ясады?

1)эт
2)аю
3) песи
4) уенчык

5.Балалар өйгә кайчан китте?

1) кич
2) төнлә
3) көндез
4) иртән

6.Кич булгач балалар кая киттеләр?

1) урамга
2) авылга
3)өйгә
4) күлгә

2 часть

При выполнении заданий этого раздела (7–8 задания),
ответы напиши кратко.

7.Балалар нишләделәр?
Җавап:_____

8.Көн нинди?
Җавап:_____

9.Кар бабайда нәрсә бар?
Җавап:_____

3 часть

На данный вопрос ответь полным предложением.

10. Кыш бабай турында яз?
Җавап:
_____
_____

II ЯРТЫЕЛЛЫК

I вариант

Текст № 5. Актүш

Безнең бик матур тутый кошыбыз бар. Ул Актүш исемле. Мин аңа татарча сүзләр өйрәттем.

Беркөнне мәктәптән кайттым һәм ашадым. Урамда малайлар көтә иде. Тутый кош миңа дәресләремне әзерләргә кушты. Мин рәхәтләнеп көлдем. Актүш турында дусларыма да сөйләдем.(39 сүз)

тутый кош — попугай
беркөнне — однажды
әзерләргә кушты — велел сделать
рәхәтләнеп — с удовольствием
(“Мәгариф” журналы, 2004 нче ел, № 8)

1 бүлек

Әлеге бүлек биремнәрен эшләгәндә (... биремнәр) дөрес җавапны саннар янында түгәрәк эчендә күрсәт.

1. Безнең нәрсә бар?

1) песи
2) кош
3) тутый кош
4) эт

2. Аның исеме ничек?

1) Актүш
2) Аккүш
3) Аккош
4) Ак

3. Мин кайдан кайттым?

1) мәктәптән
2) шәһәрдән
3) авылдан
4) урманнан

4. Мин Актүшкә нәрсә өйрәттем?

1) татарча сүзләр
2) музыка
3) русча сүзләр
4) шигырь

5)Урамда кемнәр көтте?

1) малайлар
2) апалар
3) кызлар
4) абыйлар

6)Актүш турында кемгә сөйләдем?

1) дусларга
2) абыйларга
3) әнигә
4) кызларга

2 бүлек

Бу бүлекнең биремнәрен эшләгәндә (... биремнәр) җавапларын кыскача яз.

7. Актүш нинди?

Җавап:_____

8. Малай кайдан кайта?

Җавап:_____

9. Малай дусларга нәрсә турында сөйләде?

Җавап:_____

3 нче бүлек

Түбәндәге биремдә сорауга җавапны тулы җөмлә белән яз.

10. Ә синең кечкенә дусларың бармы?

Җавап:_____

II вариант

Текст № 6. Авылда

Кечкенә Рөстәм җәй көне әнисе белән авылга әбиләренә килде. Алар үзләре бер зур шәһәрдә торалар. Рөстәмнең әле авылда булганы юк иде. Авылда әбисе аны бик ягымлы каршы алды. Ул аны тәмле әйберләр сыйлады. Рөстәм авылда матур шәһәрләре һәм трамвайлары турында сөйләде.(42 сүз) *(Нурихан Фәттахтан)*

үзләре — сами
булганы юк иде — ещё не был
ягымлы — ласково
каршы алды — встретил
сыйлады — угостил

1 часть

При выполнении заданий этого раздела (1–5 заданий), правильные ответы отметь кружочком.

1. Рөстәм авылга кем белән килде?

1) әнисе белән
2) әтисе белән
3) әбисе белән
4) абыйсы белән

2. Авылга кайчан бардылар?

1) кыш көне
2) җәй көне
3)көз көне
4) кич белән

3.Авылда кем яши?

1) бабай
2) дус
3) әби
4) Рөстәм

4. Рөстәм кайда яши?

1) дачада
2) шәһәрдә
3) авылда
4) бакчада

5. Әбисе Рөстәмне нәрсәләр белән сыйлады?

1) өчпочмак белән;
2) алмалар белән;
3) тәмле әйберләр белән;
4) ботка белән.

6. Шәһәрдә нәрсәләр бар?

1) кечкенә йортлар;
2) куяннар;
3) тавыклар;
4) зур йортлар.

2 часть

При выполнении заданий этого раздела (7–8 задания), ответы напиши кратко.

7. Рөстәм нәрсә турында сөйләде?

Җавап:_____

8. Рөстәм авылда яшиме?

Җавап:_____

9. Ә сиңа авыл ошыймы?

Җавап:_____

3 часть

На данный вопрос ответь полным предложением.

10. Рөстәм турында яз.

Җавап:_____

_____

_____

III СЫЙНЫФ

Кереш тикшерү

I вариант

Текст №1. Урман

Менә урман. Урман зур һәм матур. Анда бик күп агач үсә, төрле җәнлекләр яши.

Әнә аю. Аю җәй дә, кыш та җылы тун кия. Ул бал һәм җиләк ярата. Кыш көне аю йоклый.

Менә усал бүре. Ул ач. Бүре тиз йөгерә. Җәнлекләр бүредән курка. (45 сүз)

(“Мәгариф” журналы, 2004 нче ел, № 12)

җәнлекләр — звери
тун — шуба
усал — злой
ач — голодный

1 часть

При выполнении заданий этого раздела (1–5 задания), правильные ответы отметь кружочком.

1. Урманда нәрсәләр үсә?

1) агачлар
2) гөмбәләр
3) чәчәкләр
4) үләннәр

2. Кышын аю нишли?

1) уйный
2) ял итә
3) йоклый
4) ашый

3. Җәнлекләр нәрсәдән курка?

1) аюдан
2) песидән
3) бүредән
4) куяннан

4. Бүре нинди?

1) усал
2) начар
3) яхшы
4) әйбәт

5.Аю нәрсә кия?

1) тун
2) куртка
3) пәлтә
4) күлмәк

6.*Аю нәрсә ярата?*

1) алма
2) груша
3) бал
4) лимон

2 часть

При выполнении заданий этого раздела (6–8 задания), ответы напиши кратко.

7. Урман нинди?
Җавап:_____

8. Аю нәрсә ярата?
Җавап:_____

9. Бүре ничек йөгерә?
Җавап:_____

3 часть

На данный вопрос ответь полным предложением.

10. Урман турында яз?
Җавап:_____

II вариант

Текст №2. Өч аю
Бу кечкенә өйдә өч аю яши икән. Аларның берсе — әтиләре. Аны Михаил Иванович дип атаганнар. Ул тузгыган йонлы һәм бик зур аю булган. Икенчесе — әниләре. Ул буйга бераз кечерәк. Аны Настасия Петровна дип йөрткәннәр. Өченчесе — кечкенә генә бер аю баласы. Аңа Мишутка дип дәшкәннәр. (46 сүз)
(Л. Н. Толстойдан)
тузгыган йонлы — взъерошенный
буйга — по росту(здесь)
йөрткәннәр — называли
дәшкәннәр — обращались
чыгып киткәннәр — ушли

1 часть

При выполнении заданий этого раздела (1–5 задания),
правильные ответы отметь кружочком.

1. Кечкенә өйдә нәрсәләр яши?
1) бүреләр
2) аюлар
3) тавыклар
4) куяннар

2. Аюлар кайда яшиләр?

1) зоопаркта
2) авылда
3) урманда
4) урамда

3. Михаил Иванович нинди булган?

1) кечкенә һәм матур
2) ак һәм зур
3) пычрак һәм кара
4) бик зур

4. Икенче аюның исеме ничек?

1) Анна Егоровна
2) Агата Викторовна
3) Елена Сергеевна
4) Настасия Петровна

5. Гаиләдә ничә аю булган?

1) ике
2) биш
3) өч
4) дүрт

6. ***Кечкенә аюның исеме ничек?***

1) Степашка
2) Андрюша
3) Павлуша
4) Мишутка

2 часть

При выполнении заданий этого раздела (6–8 задания), ответы напиши кратко.

7. Беренче аюның исеме ничек?

Җавап:_____

8. Кечкенә аюның исеме ничек?

Җавап:_____

19. Әкиятнең авторы кем?

Җавап:_____

3 часть

На данный вопрос ответь полным предложением.

10. ***Аюлар турында яз.***

Җавап:_____

_____

I ЯРТЫЕЛЛЫК

I вариант

Текст №3. Кыш килде

Декабрь ае килеп җитте. Урамда салкыннан бит, куллар кып-кызыл була, аяклар туңа. Шуңа күрә кешеләр җылы киенә.

Урамда көн буе кар ява. Бөтен җир ап-ак булды. Агачлар да җылы туннарын киде.

Урманда да кар күп. Куяннар хәзер соры туннарын салды. Аларга җылы ак йон үсте. Ак карда куяннарны бүреләр һәм төлкеләр күрми. Куян тиз йөгерә. Ул шулай усал бүреләрдән кача. (60 сүз)

туңа — мёрзнет

килеп җитте — пришла

тун — шуба

йон — шерсть

кача — прячется

(“Мәгариф” журналы, 2004 нче ел, № 8)

1 бүлек

Әлеге бүлек биремнәрен эшләгәндә (... биремнәр) дөрес җавапны саннар янында түгәрәк эчендә күрсәт.

1. Текстта нинди ай турында язылган?

1) декабрь
2) январь
3) февраль
4) ноябрь

2. Кешеләр ничек киенә?

1) яхшы
2) матур итеп
3) кызык итеп
4) җылы

3. Урамда кар кайчан ява?

1) иртән
2) көндез
3) кичен
4) көне буе

4. Агачлар нинди киемнәрен киделәр?

1) күлмәк
2) итәк
3) тун
4) чалбар

5. Урманда нәрсә күп?

1) каеннар
2) бүреләр
3) куяннар
4) кар

6. Куянга кыш көне нәрсә үсә?

1) зур колаклар
2) озын койрык
3) аяклар
4) җылы ак йон

2 бүлек

Бу бүлекнең биремнәрен эшләгәндә (... биремнәр) җавапларын кыскача яз.

7. Куяннар кышын нинди туннарын кияләр?

Җавап:_____

8. Куян нәрсәләрдән курка?

Җавап:_____

9. Текстта нинди хайваннар турында язылган?

Җавап:_____

3 нче бүлек

Түбәндәге биремдә сорауга тулы җөмлә белән җавап яз

10. Куян усал бүреләрдән ничек кача?

Җавап:_____

II вариант

Текст № 4. Татарстан

Без Татарстанда яшибез. Татарстан бик зур һәм бай. Анда Казан,Чистай, Алабуга, Бөгелмә, Әлмәт, Чаллы, Түбән Кама һәм башка шәһәрләр бар.

Татарстанда зур елгалар ага. Татарстанны Идел, Кама, Агыйдел, Зәй, Ык , Мишә, Нократ, Казансу елгалары бизи. Ул шулай ук яшел тугайларга,куе урманнарга, түгәрәк күлләргә бай.

Казан — Татарстанның башкаласы. Казанга бер мең яшь инде. (54 сүз)

1 бүлек

Әлеге бүлек биремнәрен эшләгәндә дөрес җавапны саннар янында түгәрәк эчендә күрсәт.

1. Без кайда яшибез?

1) Татарстанда
2) Иделдә
3) Казанда
4) шәһәрдә

2. Татарстанның башкаласы —

1) Казан
2) Алабуга
3) Мәскәү
4) Әлмәт

3. Татарстан нинди?

1) бай
2) яшел
3) кечкенә
4) матур

4. Татарстан нәрсәләргә бай?

1) урманнарга
2) авылларга
3) кырларга
4) шәһәрләргә

5. Казанга ничә яшь ?

1) мең
2) ике мең
3) йөз
4) ике йөз

6.Текстта ничә елга исеме бирелгән?

1) 6
2) 7
3) 8
4) 9

2 бүлек

Бу бүлекнең биремнәрен эшләгәндә (... биремнәр) җаваплары кыскача яз.

7. Татарстанда нинди елгалар бар?

Җавап:_____

8. Татарстанда нинди шәһәрләр бар?

Җавап:_____

9. Татарстан нинди?

Җавап:_____

3 бүлек

Түбәндәге биремдә сорауга тулы җөмлә белән җавап яз

10. Татарстан турында яз.

Җавап:_____
_____
_____

II ЯРТЫЕЛЛЫК

I вариант

Текст № 5. Минем энем

Мин энем Рөстәм белән кышкы каникулда әбиләрдә кунакта булдым. Безне каршы алдылар.

Әби самовар куйды. Самовар артыннан ит сумсалары, алма, конфетлар, хуш исле бал өстәлгә куелды.

Әби тәлинкәгә өч сумса куйды. Мин бер алма алып бирдем.

Рөстәм бик әдәпле булды. Ул ашыкмый гына ашады һәм ашъяулыкка тап төшермәде.

(Д.Аппакова буенча) (48 сүз)

тап — пятно

сумса — пирожок

ашыкмый — не торопясь

1 бүлек

Әлеге бүлек биремнәрен эшләгәндә (1–7 нче биремнәр) дөрес җавапны саннар янында түгәрәк эчендә күрсәт.

1. Кышкы каникулда без кайда булдык?

1) әбиләрдә
2) апаларда
3) бабайларда
4) шәһәрдә

2. Рөстәм нинди малай?

1) кечкенә
2) начар
3) әдәпле
4) яхшы

3.Әби нәрсә куйды?

1) самовар
2) кәстрүл
3) чәйнек
4) чынаяк

4. Тәлинкәгә нәрсә куйдылар?

1) сумса
2) бәлеш
3) өчпочмак
4) печенье

5.Әбиләрдә кайчан булдык?

1) кышкы каникулда
2) көзге каникулда
3) җәйге каникулда
4) язгы каникулда

6.Рөстәм ничек ашады?

1) ашыгып
2) ашыкмый гына
3) тиз
4) әкрен

7. Хикәянең авторы кем?

1) Абдулла Алиш
2) Габдулла Тукай
3) Резеда Вәлиева
4) Дәржия Аппакова

2 бүлек

Бу бүлекнең биремнәрен эшләгәндә (8– нчы биремнәр) җавапларын кыскача яз.

8.Төп геройларны яз.

Җавап:_____

9.Өстәлгә нәрсәләр куйдылар?

Җавап:_____

10. Мин Рөстәмгә нәрсә бирдем?

Җавап:_____

3 нче бүлек

Түбәндәге биремдә сорауга тулы җөмлә белән җавап яз

11. Сез каникулда кая барасыз?_____

II вариант

Текст № 6. Безнең бакча

Безнең авыл тау буенда утыра.Ерак түгел бер инеш бар.Ерак түгел бер инеш бар.Балык күп анда.Эссе көннәрдә без инештә су керәбез.

Мәктәп янында бакчабыз бар.Анда алмагачлар,чияләр үсә. Аларны утырткан малайлар һәм кызлар укып чыкканнар инде.

Әнә яшелчә бакчасы. Аны без утырттык, үстерәбез.Быел кәбестә,кыяр,суган,помидор бик яхшы үсә. (55 с)

(Г.Бакировтан)

инеш — ручей

1 нче бүлек

Әлеге бүлек биремнәрен эшләгәндә (1–7 нче биремнәр) дөрес җавапны саннар янында түгәрәк эчендә күрсәт.

1. Безнең авыл кайда?

1) тау буенда
2) шәһәр янында
3) урман янында
4) күл янында

2. Авыл янында нәрсә бар?

1) урман
2) инеш
3) тау
4) елга

3. Инештә нәрсә бар?

1) бака
2) агачлар
3) балык
4) алтын

4. Мәктәп янында нәрсә бар?

1) тау
2) парк
3) бакча
4) агачлар

5. Бакчада нәрсәләр үсә?

1) чияләр
2) агачлар
3) чәчәкләр
4) үлән

6. Эссе көннәрдә без нишлибез?

1) су керәбез
2) ашыйбыз
3) уйныйбыз
4) йөгерәбез

7. Бакчаны кемнәр утырткан?

1) бабайлар
2) әтиләр
3) малайлар, кызлар
4) әниләр, әбиләр

2 нче бүлек

Бу бүлекнең биремнәрен эшләгәндә (8–9 нчы биремнәр) җавапларын кыскача яз.

8. Ә синең бакчаң бармы?

Җавап:_____

9. Бакчада нәрсәләр үсә?

Җавап:_____

10. Быел без нәрсәләр утырттык?

Җавап:_____

3 нче бүлек

Түбәндәге биремдә сорауга тулы җөмлә белән җавап яз

11. Бакчаң турында яз.

Җавап:_____

IV СЫЙНЫФ

Кереш тикшерү

I вариант

Текст №1. Әтәч белән Төлке

(татар халык әкияте)

Бервакыт Төлке авылга килде. Ул әтәчне күрде. Әтәч койма башында утыра иде. Төлке әтәчкә әйтте:

— Әй, дус, әйдә, койма башыннан төш! Бергә качышлы уйныйк!

Әтәч әйтте:

— Уенны алып баручы агач артында йоклый. Син аны уят, - диде.

Төлке карады, этне күрде. Эт агач артында ята. Төлке курыкты һәм китә башлады.

Әтәч әйтте:

— Кая барасың, Төлке? Бергә качышлы уйнамыйбызмы? — диде.

Төлке:

— Хәзер уйныйбыз. Мин күз бәйләвече генә алып киләм, - дип, койрыгын күтәрде һәм качты. (72 сүз)

качышлы — в прятки
алып баручы — ведущий
уят — разбуди
күз бәйләвече — повязка на глаза
койма — забор

1 нче бүлек

Әлеге бүлек биремнәрен эшләгәндә (1–7 нче биремнәр) дөрес җавапны саннар янында түгәрәк эчендә күрсәт.

1. Бервакыт төлке кая килде?

1) авылга
2) шәһәргә
3) бакчага
4) урманга

2. Төлке кемне күрде?

1) тавыкны
2) кәҗәне
3) песине
4) әтәчне

3. Әтәч кайда утыра иде?

1) бакчада
2) сарайда
3) агач башында
4) койма башында

4. Төлке нинди уен уйнарга теләде?

1) качышлы
2) шахмат
4) йөгерешле
3) утырышлы

5. Эт кайда йоклый иде?

1) караватта
3) агач артында
2) бакчада
4) агач янында

6. Кем уенны алып баручы булырга тиеш иде?

1) эт
3) бүре
2) юлбарыс
4) аю

7. Төлке нәрсә алырга китте?

1) алма
3) күз бәйләвече
2) тавык
4) уенчык

2 нче бүлек

Бу бүлекнең биремнәрен эшләгәндә (8–10 биремнәр) җавапларын кыскача яз.

8. Төлкенең яраткан ризыгы?

_____

9. Төлке ни өчен китте?

_____

10. Әкияттә кем хәйләкәррәк булып чыкты?

_____

3 нче бүлек

Түбәндәге биремдә сорауга тулы җөмлә белән җавап яз

11. Төлке турында нәрсәләр беләсең?

_____

II вариант

Текст №2. Теремкәй
(Рус халык әкияте)
Басуда терем-теремкәй бар.
Бер тычкан — Чыелдык теремкәй янына чабып килгән :

— Терем-теремкәйдә кем яши? — ди. Җавап юк. Тычкан теремкәйгә керә дә яши башлаган.

Беркөнне теремкәй янынан бака-Бакылдык үтеп бара икән, ул туктаган да сораган:

— Терем-теремкәй! Теремкәйдә кем яши?

— Мин, тычкан-Чыелдык. Ә син кем буласың?

— Мин бака-Бакылдык .

— Әйдә кер, бергә торырбыз.

Бака-Бакылдык теремкәйгә кергән, алар икәү яши башлаганнар.Бервакыт теремкәй янына куян-Куркак килгән. Ул да сораган:

— Терем-теремкәйдә кем яши? — дигән.

— Мин, тычкан-Чыелдык.

— Мин, бака-Бакылдык. Ә син кем буласың?

— Мин куян-Куркаккай булам.

— Әйдә, алайса, кер. Бергә-бергә яшәрбез.(84 сүз)

1 нче бүлек

Әлеге бүлек биремнәрен эшләгәндә (1–7нче биремнәр) дөрес җавапны саннар янында түгәрәк эчендә күрсәт.

1. Басуда нәрсә бар?

1) йорт
2) бакча
3) теремкәй
4) урман

2. Теремкәйгә нәрсә килә?

1) песи
2) эт
3) тычкан
4) бабай

3. Теремкәйдә нәрсәләр яши?

1) бака
2) бүре
3) песи
4) эт

4. Теремкәйдә ничә герой яши?

1) 4
2) 2
3) 3
4) 5

5. Әкиятнең авторы кем?

1) Абдулла Алиш
2) Габдулла Тукай
3) рус халык әкияте
4) татар халык әкияте

6. Теремкәйдә кайсы герой яши башлаган?

1) тычкан
2) куян
3) бака
4) аю

7. Әкияттә куянның тулы исеме ничек?

1) Куян-йомшаккай
2) Куян-матуркай
3) Куян-аккай
4) Куян-куркаккай

2 нче бүлек

Бу бүлекнең биремнәрен эшләгәндә (8–9 нчы биремнәр) җавапларын кыскача яз

8. Төп геройлар ?

Җавап:_____

9. Теремкәйгә беренче нәрсә килә?

Җавап:_____

10. Тычкан-Чыелдык,бака-

Җавап:_____

3 нче бүлек

Түбәндәге биремдә сорауга тулы җөмлә белән җавап яз

11. Геройлар турында кыскача яз .

Җавап:_____
_____
_____

I ЯРТЫЕЛЛЫК

I вариант

Текст № 3. Каен кызы

Күптән түгел генә җәй иде. Зәңгәр күктә кояш көлә. Яшел болында матур-матур чәчәкләр үсә. Чәчәкләрдә күбәләкләр уйный.

Менә җылы җәй үтеп тә китте. Яңгырлы көз килде. Хәзер көннәр кыска, төннәр озын. Кояш күктә бик аз күренә. Көндез дә, төнлә дә яңгырлар ява.

Тәрәзә алдында үскән каен кызына бик күңелсез. Чөнки ул хәзер берүзе генә калды. Каенның сары яфраклары һәм дус кошлары очып китте. Аның белән хәзер салкын җил генә уйный. Ә каен кызы салкыннан бик курка. (76)

Тиздән ак карлы кыш килер. Каен кызы салкында туңар. Ләкин аны Кыш бабай бик тиз күреп алыр. Ул каен кызына ап-ак яулык, йомшак тун бүләк итәр. Каен кызы язга кадәр җылыда яшәр. (108)

болын — луг
күбәләк — бабочка
күренә — виднеется
берүзе — одинокий
яулык — платок

1 нче бүлек

Әлеге бүлек биремнәрен эшләгәндә (1–7нче биремнәр)
дөрес җавапны саннар янында түгәрәк эчендә күрсәт.

1.Чәчәкләрдә нәрсәләр уйный?

1) кошлар
2) куяннар
3) күбәләкләр
4) песиләр

2.Кайсы ел вакыты җитте?

1)көз
2)кыш
3) яз
4) җәй

3.Көз нинди?

1) болытлы
2) кояшлы
3)яңгырлы
4) карлы

4.Тәрәзә алдында нәрсә үсә?

1) каен кызы
2) имән
3) каен малае
4) нарат

5.Каен кызы белән нәрсә генә уйный?

1) болыт
2) күбәләк
3) җил
4) аю

6.Тиздән нинди ел вакыты җитәр?

1) яз
2) кыш
3) җәй
4) көз

7.Кыш бабай Каен кызына нәрсә бирер?

1) тун
2) бияләй
3) пәлтә
4) кәнфит

2 нче бирем

Бу бүлекнең биремнәрен эшләгәндә (8–10 нчы биремнәр)
җавапларын кыскача яз.

8. Хикәя нәрсә турында?

Җавап:_____

9. Болында нәрсәләр үсә?

Җавап:_____

10.Каен кызы нәрсәдән курка?

Җавап:_____

3 нче бирем

Түбәндәге биремдә сорауга тулы җөмлә белән җавап яз

11.Каен кызы турында яз.

Җавап:_____

_____

II вариант

Текст № 4. Кем нәрсә ярата?

(татар халык әкияте)

Бер йортта Песи белән Эт, Әтәч һәм Кәҗә яшиләр. Кичен алар табын әзерлиләр. Өстәлгә тәлинкәләр, чынаяклар,кашыклар куялар. Алар өстәл артында сөйләшәләр:

— Мин сөт яратам,— ди Песи.— Ул тәмле һәм файдалы.

— Нәрсә беләсең син? Мин сөт яратмыйм. Иң тәмле ашамлык — карабодай,дөге һәм бодай ,-ди Әтәч.

— Юк-юк! —, ди Акбай. Иң тәмле һәм файдалы ризык — ит. Нинди азык тәмле, нинди азык файдалы икәнен миннән дә әйбәт белгән хайван юк.

— Нәрсә-ә-ә сөйлисең син, — ди Кәҗә.— Менә мин ит яратмыйм,мин кәбестә-ә ашарга яратам. Иң тәмле азык — ул кәбес-тә-ә-ә! — ди ул.

Алар сөйләшәләр, сөйләшәләр — килешә алмыйлар. (92 сүз)

дөге — рис
табын — стол с угощениями
азык — еда
бодай — пшеница

1 нче бүлек

Әлеге бүлек биремнәрен эшләгәндә (1–7 биремнәр)
дөрес җавапны саннар янында түгәрәк эчендә күрсәт.

1. Хайваннар кайда яши?

1) йортта
2) авылда
3) урманда
4) шәһәрдә

2. Хайваннар өстәлгә нинди савыт-саба куялар?

1) тәлинкәләр, чынаяклар, кашыклар
2) чәйнек, чынаяк, тәлинкәләр
3) тәлинкәләр, кәстрүл, пычаклар
4) чынаяклар, кашыклар, алмалар

3. Кем сөт ярата?

1) Акбай
2) Кәҗә
3) Песи
4) Әтәч

4. Кем ит ярата?

1) Песи
2) Кәҗә
3) Әтәч
4) Акбай

5. Кем кәбестә ярата?

1) Песи
2) Кәҗә
3) Акбай
4) Әтәч

6. Кем сөт яратмый?

1) Әтәч
2) Акбай
3) Песи
4) Кәҗә

7. Кем ит яратмый?

1) Акбай
2) Әтәч
3) Кәҗә
4) Песи

2 нче бүлек

Бу бүлекнең биремнәрен эшләгәндә (8–10 биремнәр) җавапларын кыскача яз.

8. Синең өчен нәрсәләр файдалы?

Җавап:_____

9. Төп геройларны яз.

Җавап:_____

10. Әтәч нәрсә ярата?

Җавап:_____

3 нче бүлек

Түбәндәге биремдә сорауга тулы җөмлә белән җавап яз

11.Ә син нәрсә яратасың? Кыскача яз.

Җавап:_____

II ЯРТЫЕЛЛЫК

I вариант

Текст № 5.Шалкан

Бабай шалкан утыртты. Шалкан көн үсте, төн үсте, бик зур булды.

Атналар, айлар үтте, җәй үтте, көз җитте. Бабай шалканны тарта, тарта — шалкан чыкмый. Бабай әбине чакырды. Әби — бабайга, бабай шалканга тотынды. Әй тарталар, әй тарталар — шалкан чыкмый. Әби кызын чакырды. Кыз — әбигә, әби — бабайга, бабай шалканга тотына.Әй тарталар, әй тарталар — шалкан чыкмый.

Кыз шалканны тартырга Акбайны чакырды. Акбай — кызга, кыз — әбигә, әби — бабайга, бабай шалканга тотынды. Әй тарталар, әй тарталар — шалкан чыкмый, селкенми дә.

Акбай песине чакырды. Песи — Акбайга, Акбай — кызга, кыз — әбигә, әби — бабайга, бабай шалканга тотынды.

Әй тарталар, әй тарталар — шалкан чыкмый.

Песи тычканны чакырды. Тычкан — песигә, песи — Акбайга, Акбай — кызга, кыз — әбигә,әби — бабайга, бабай шалканга тотынды . Шалкан чыкты. (114 сүз)

1нче бүлек

Әлеге бүлек биремнәрен эшләгәндә (1–7 биремнәр) дөрес җавапны саннар янында түгәрәк эчендә күрсәт.

1. Шалканны кем утырта?

1) әби
2) әни
3) бабай
4) кыз

2. Бабай нәрсә утырта?

1) шалкан
2) бәрәңге
3) кишер
4) алма

3. Кем шалканны икенче булып тарта?

1) Әби
2) бүре
3) Куян
4) төлке

4. Шалкан нинди?

1) кечкенә
2) зур
3) тәмле
4) тәмсез

5. Песи кемне чакыра?

1) тычканны
2) бабайны
3) кызны
4) этне

6. Кыз кемне чакыра?

1) малайны
2) Акбайны
3) песине
4) Тычканны

7. “Шалкан”да ничә персонаж бар?

1) биш
2) җиде
3) ун
4) алты

2 нче бүлек

Бу бүлекнең биремнәрен эшләгәндә (8–10 биремнәр), җавапларын кыскача яз.

8. Шалканны кемнәр тарта?

Җавап:_____

9. Син шалкан яратасыңмы?

Җавап:_____

10. Бу әкиятме, хикәяме?

Җавап:_____

3 нче бүлек

Түбәндәге биремдә сорауга тулы җөмлә белән җавап яз

11. Син нинди яшелчәләр яратасың?

Җавап:_____

_____

II вариант

Текст № 6. Аю Әппәс

Бер бәләкәй аю баласы яши урманда. Бәләкәй булса да бу аю баласы бик эшчән булган. Бу аю баласының исеме Әппәс булган. Әппәс яз көне бакча казыган. Бер түтәлгә кишер чәчкән. Кәбестә ,кыяр да утырткан.Помидор белән шалкан да үстергән ул.

Көз җиткән. Бәләкәй аю баласы кишерне ,кәбестәне дә алган, кыяр белән помидорны да,шалканны да җыйган.

— Мәм-мәм-мәм, баллы, тәмле, татлы ! — ди икән.

Шулчак Куян бара икән. Куянның ашыйсы килә .

— Аю Әппәс, бир әле миңа да тәмле әйбер! — дигән Куян.

— Мә! — дигән аю баласы. Куянга бер кишер, бер кәбестә, бер кыяр, бер помидор, бер шалкан биргән.

— Мәм-мәм, баллы икән болар! — дигән Куян.

— Рәхмәт, сиңа, Әппәс, рәхмәт.

Шулчак Керпе килгән .

— Мә! Син дә авыз ит! — дип, Әппәс Керпегә дә яшелчә биргән.

— Мәм-мәм, татлы икән болар! — дигән Керпе.

— Рәхмәт сиңа, Әппәс!

Шулчак Тиен килгән .

— Тиен, син дә аша баллы яшелчә! — дигән аю .

Аю барысын яшелчәләр белән сыйлаган . Әппәскә рәхмәт әйткәннәр .

Кыш җиткән. Бәләкәй Әппәс йокларга яткан. (153 сүз)

(Рабит Батулла)

1нче бүлек

Әлеге бүлек биремнәрен эшләгәндә (1–7 биремнәр) дөрес җавапны саннар янында түгәрәк эчендә күрсәт.

1.Аюның исеме ничек?

1) Әппәс.
3) Йомшак
2) Әннәс
4) Бәләкәй

2.Әппәс нәрсәләр утырткан?

1) яшелчәләр
3) бәрәңге
2) кабак
4) чөгендер

3. Аю кайда яши?

1)урамда
3) урманда
2) авылда
4) шәһәрдә

4. Аю нинди?

1) эшчән
3) ялкау
2) тырыш
4) зур

5. Аю кайчан йоклый?

1) яз көне
3) кыш көне
2) җәй көне
4) көз көне

6. Әппәс нәрсә белән сыйлаган?

1) алма белән
3) яшелчәләр белән
2) җиләк белән
4) кәнфит белән

7. Әкияттә нинди герой юк?

1) эт
3) куян
2) тиен
4) аю

2 нче бүлек

Бу бүлекнең биремнәрен эшләгәндә (8–9 нчы биремнәр) җавапларын кыскача яз.

8. Син нинди яшелчәләр яратасың?

Җавап:_____

9. Әппәс нинди аю?

Җавап:_____

10. Аю баласы куянга нәрсәләр бирә?

Җавап:_____

3 нче бүлек

Түбәндәге биремдә сорауга тулы җөмлә белән җавап яз.

11. *Әппәс турында 3 җөмлә яз*.

Җавап:_____

_____

РЕЗЕРВ

Тиздән яңа ел

Менә салкын кыш көннәре дә килеп җитте. Көннәр кыска, ә төннәр озын. Көндез дә, төнлә дә кар ява. Бөтен җир ап-ак. Кешеләр җылы киемнәрен киеп йөри башладылар.

Тиздән Яңа ел бәйрәме җитәр. Без яшел чыршыны бизәргә уенчыклар ясарбыз. Бәйрәм бик күңелле булыр. (42 сүз)

киеп йөри башлады — начали носить (одежду)

бизәргә — украшать